*Ий, мөэминнәр! Барчаларыгыз да бирләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә нык ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!*
*(Коръәни-Кәрим, 3:103.)*

# ДИН вә Мәгыйшәт

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ • №1 (222) ГЫЙНВАР 2014/ РАБИГЫЛЬ-ӘҮВӘЛ 1435

# МӘҮЛИД МӨБАРӘК БУЛСЫН!





***Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!***

Татарстан мөселманнары Дinduced нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны да Мәүлид бәйрәме белән ихластан котлыйм!

“Мәүлид” – туу, туган вакыт мәгънәсен аңлата. Мәүлид кичәсе дөньяга соңгы пәйгамбәр буларак җибәрелгән сөекле Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) туган көне. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган вакыты милади исәпнең 571 нче елына туры килә. Мәүлид – рабигыль әүвәл аеның 11-12 нче көннәре арасындагы кичә. Коръәндә әйтелә: **“(Әй, Мөхәммәд) Без сине бары рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек”** ***(“Әнбия (Пәйгамбәрләр)” сүрәсе, 107 нче аять).*** Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормышы, камил холкы һәр мөселман өчен өлге, үрнәк булып тора, нәсыйхәтләре калебләребезне ныгыта, күңелләребезне нурлы итә. Хәдисләре гыйлемле булырга, сабырлыкка, юмартлыкка өйрәтә.

Мәүлид кичәсендә догалар уку вә тыңлау, дини мәҗлесләр корып салаватлар әйтү, хәер-сәдакалар өләшү – Бөек Раббыбыз һәм Аның Рәсүленә (с.г.в.) карата ихласлыгыбызны күрсәтә, Пәйгамбәребез (с.г.в.) туган кичәне хөрмәт итү булып тора. Мәүлид кичәсе – бер-беребезгә карата кардәшлек хисләрен ныгыту, хөрмәт итүне арттыру көне дә.

Шушы күркәм Мәүлид кичәсендә шөкрана кылыйк, дин кардәшләребез белән бергә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) багышлап һәм бер-беребезгә иминлек, бәрәкәт сорап догалар кылыйк. Һәрбарчабызга да Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең рәхим-шәфкате язсын! Өммәтебезгә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сөннәтенә ияргән хәлдә яшәргә насыйп итсә иде!

**Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе**

## БҮГЕНГЕ САНДА:



**«БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ИШЕТӘ БАШЛАДЫК»**

**6 нчы бит**



**ИСЛАМНЫ НИЧЕК КАБУЛ ИТӘРГӘ?**

**11 нче бит**



**БУЙДАК БУЛУ ХӘРАММЫ?**

**13 нче бит**

**ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘННӘН АЯТЬЛӘР БАР, АНЫ ТИЕШСЕЗ УРЫНГА КУЛЛАНУДАН САКЛАНЫГЫЗ!**

### Татарстан мөфтие Мәскәүдә Мәүлид бәйрәмендә катнашты

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә ТР МДН делегациясе 26 гыйнварда Мәскәүдә үткәрелгән Мәүлид ән-Нәби бәйрәмендә катнашты. Делегация составына мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр, нәзарәт вәкилләре һәм башка дин әһелләре кергән иде. Татарстан мөфтиенең Мәскәүдә берничә очрашуы булды. Аерым алганда, ул Россия Мөфтиләр шурасы рәисе шәех Равил хәзрәт Гайнетдин, Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Илдар хәзрәт Әлаутдинов белән очрашты. Мәскәүнең Crocus City Hall залында үткәрелгән бәйрәмдә татар, рус, ингуш, кыргыз, гарәп, инглиз телләрендә динебезгә, Пәйгамбәргә (с.г.в.) багышланган мөнәҗәтләр башкарылды.

### Мәдрәсәләр өчен әсбаплар исемлеге расланды

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтен-дә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә уздырылган киңәшмәдә дини белем бирүче урта һөнәри мәдрәсәләр өчен төп уку әсбаплары исемлеге расланды. Исемлеккә дөньякүләм танылган «Нур әл-изах», "Мохтасәр әл-Кудури", "Тәфсир әл-Җәләлән", "әл-Манар" кебек китаплар керде. Әлеге китаплар инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә укытылган хезмәтләр. Классик хезмәтләрдән тыш исемлектә инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә киң таралыш алган Әхмәтһади Максудиның "Мөгаллим сәни", "Гыйбадәт әл-Исламия", Габдрахман Карабашның "Тәҗвит Карабаш" китаплары да бар.

### Казан мөселманнарына "Бәхетле" ишекләре ачылды

Казан һәм бигрәк тә аның Иске Татар бистәсе мөселманнары өчен шатлыклы вакыйга булды. Биредә хәләл ризыкның бик күп төрләре тәкъдим ителгән "Бәхетле" супермаркеты эшли башлады. Кибетләр челтәре җитәкчесе Мөслимә ханым Латыйпова, мөселманнарның теләген искә алып, Тукай урамындагы 64 нче йортта яңа сәүдә урыны булдырды. Биредә сатып алучыларга ТР МДН "Хәләл" комитеты тикшерүе узган 10 меңнән артык товар тәкъдим ителәчәк. Шулай ук гарәп илләреннән кайтартылган һәм "Бәхетле" үзе ислам кануннары буенча әзерләгән ризыкларны сатып алып булачак.

*Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# ДИНИ ГОРЕФ - ГАДӘТЛӘРНЕ ТОРГЫЗУ ЕЛЫНА АЯК БАСТЫК



**Мәүлид бәйрәме чарасы алдыннан Болгарда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең быелгы беренче күчмә пленумы утырышы үткәрелде. Пленум утырышында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, казыйлар, Голәмалар шурасы әгъзалары, мөхтәсибләр катнашты. Әлеге сөйләшүдә Татарстан дин әһелләре 2014 нче елга дини эшчәнлекнең төп чараларын, юнәлешләрен билгеләделәр.**

Утырышта мөфти Камил хәзрәт барлык имамнарны Мәүлид белән котлады һәм: "Узган елда башланган күркәм эшләр бар. Кайберләрен санап үтәм: дәгъвәтне һәм социаль эшләрне ныгыту; "Хузур" нәшрият йортын эшләтү, яшь имамнарга грантлар бирү, мәдрәсәләргә укыту программаларын әзерләү, югары дәрәҗәдә хаҗны оештыру, хәләл сферасын үстерү һәм башкалар. Быел да боларның һәркайсын дәвам итү бик мөһим. Дәгъвәт, социаль мәсьәләләр, имамнарны кайгырту һәм мирасны өйрәнү - нәзарәтнең төп эшләре",- дип билгеләп үтте. Быел үткәреләчәк чараларга тукталып, 2014 нче елны Дини гореф-гадәтләрне торгызу елы буларак үткәрергә тәкъдим итте. "Бу ел барыбыз өчен татар халкының дини рухын ныгыту елы булырга тиеш", - диде ул.

Утырышта Татарстанның иң үрнәк имамын ачыкларга кирәк, дигән карарга да киленде. СМС-хәбәр аша тавыш биреп, Ел имамы сайланачак һәм ул хаҗга җибәреләчәк. Тавыш биргәндә имамнарның дини укулар оештыруы, дини чаралар уздыруы, мәхәллә халкы белән уртак тел табып эшләве исәпкә алыначак.

Җыелышта Татарстанның һәр районы өчен намаз вакытларының төгәл вакытын ачыклау буенча фикер алыштылар. Бу уңайдан Голәмалар шурасы рәисе Габдулла хәзрәт Әдһәмов, шура әгъзасы Равил хәзрәт Бикбаев чыгышлары тыңланды. Дин әһелләре намаз вакытларын билгеләгәндә астрономик исәпләүләргә таянырга килештеләр.

**Февраль аеннан намаз вакытларында берникадәр үзгәрешләр булачак. Бу нәрсә белән бәйле соң? Әлеге сорауны без Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы, башкалабызның Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт БИКБАЕВка бирдек.**



# АСТРОНОМНАР НАМАЗ УКУНЫҢ ТӨГӘЛ ВАКЫТЫН БИЛГЕЛӘДЕ

– Аллаһы Тәгалә "Ниса" сүрәсенең 103 нче аятендә: "...Намаз мөселманнарга төгәл вакытларда укылырга фарыз ителгән гыйбадәттер", - ди. Намаз, вакыты кергәнчегә кадәр укылса - дөрес түгел; вакыты чykканнан соң укылса - казага калган булып исәпләнә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә Мигъраҗ кичәсендә биш вакыт намаз фарыз булганнан соң, Җәбраил фәрештә килеп, аңа намазның вакытларын өйрәтә. Ул беренче көнне килеп, һәр намазның беренче вакытында укый. Икенче көнне килеп, һәр намазның ахыргы вакытында укый. Аннары: "Менә бу вакытлар арасында намазларыгызны укыгыз", - дип әйтә. Шуңа таянып, безнең галимнәребез: "Иртәнге намазның вакыты таң беленә башлап, тарала башлагач керә һәм кояш чыга башлаганчы дәвам итә. Өйлә намазы кояш иң биек ноктадан авышканнан алып берәр әйбернең шәүләсе 2 тапкырга артканчыга хәтле. Икенде намазы өйлә намазыннан соң кояш баенганчыга хәтле. Ахшам кояш баеганнан соң шәфәкъ кызыллыгы беткәнчегә хәтле. Ястү намазы шәфәкъ кызыллыгы яки аклыгы бетеп, иртәнге намазның вакыты кергәнчегә хәтле, ләкин төн уртасыннан соңгарак калдыру мәкрүһ санала", - диләр. Күренгәнчә, намаз вакытлары кояш йөрешенә бәйле. Кояшны Хак Тәгалә төгәл йөри торган итеп ясаган. Аның йөрешен исәпләп була. Шуңа да мөселман астрономнары IX гасырда ук таң атуны һәм шәфәкъ кызыллыгы яки аклык бетүне градуслар белән билгеләгән. Билгеле булганча, кояш баегач, горизонттан югала. Кояш горизонттан ерагайган саен, безгә күренгән шәфәкъ кызыллыгы кимеп бара һәм бер микъдарны узып киткәч, шәфәкъның башта кызыллыгы, аннан соң аклыгы бетә. Ул гадәттә 15 һәм 18 градуслар белән билгеләнә. Шуңа күрә иртәнге якта кояш 18 градуска җиткәч, таң беленергә кереша, 15 градуска җиткәч, кызыллык башлана. Ә кич белән киресенчә, 15 градуска җиткәч, шәфәкъ кызыллыгы, 18 градуста аклыгы бетә. Ә менә җәй көне, безнең җирлектә кояш искә алынган градуслардан түбәнрәк төшми һәм шул сәбәпле безнең җирлектә шәфәкъ кызыллыгы һәм аклыгы бетми. Шуңа күрә безнең галимнәребез шәфәкъ бетмәгәндә ничек ястү намазын уку мәсьәләсен күтәргән һәм шуңа багышлап күп хезмәтләр язган.

**– Равил хәзрәт, безнең татар галимнәре намаз вакытларында астрономик исәпләүләрне кулланганмы?**



# Рөстәм БАТЫР:

## «ҺӘЛАКӘТ ТУРЫНДАГЫ ФИЛЬМНАР – КЫЯМӘТ КӨНЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ВЕРСИЯСЕ»

### КЕШЕ ГОМЕРЕ – ДӨНЬЯ ТАРИХЫНЫҢ КЕЧКЕНӘ КОПИЯСЕ

XX гасырның күренекле физигы Дэвид Бом хәзерге чынбарлыкны анализлау өчен галәмнең голографик моделен тәкъдим итә. Соңгы вакытта киң таралыш алган кабарынкы рәсем иллюзиясен барлыкка китергән голограммаларда бу модельнең принцибы ачык күренә. Шунысы кызык: голограмманы ватсак, аның һәрбер кыйпылчыгында без рәсемнең бер өлешен түгел, ә бөтен рәсемне күрәчәкбез. Чынбарлыкның голографик моделе һәр күзәнәк төшендә ДНК аша кеше турында мәгълүмат саклаган кебек, дөньяның без күзәткән һәр өлешендә (голограмма кыйпылчыгындагы сыман) бөтен галәм төзелеше турында тулы мәгълүмат бар. Башкача әйткәндә, галәм - өч тигезлектәге голограмма.

Фәлсәфә өчен бу фикер яңа түгел. Борынгы заман галимнәре кешене микрокосм, ягъни макрокосмның кечерәйтелгән варианты буларак кабул иткәннәр. Кечкенә галәм буларак. Урта гасыр дини фәлсәфәсендә дә бу фикер киң таралган була. Ләкин без дөньяга мондый карашны дөрес дип исәпләсәк, ул кеше гомере агышын да чагылдырырга тиеш. Башкача әйткәндә, кеше гомеренең төп этаплары булса да дөнья тарихы этаплары белән тәңгәл килергә тиеш. Бу күзлектән чыгып карaганда, кешенең дөньяга килүе Адәм белән Һава сюжетына (ягъни кешелекнең барлыкка килүенә), ә кешенең үлүе дөнья бетүен аңлаткан Кыямәт көненә туры килә.

Мондый мотивлар дөньяви, ә кайвакыт дингә каршы булган, хәзерге заман мәдәниятендә дә күренә. Һәлакәт турындагы фильмнар - бу күренешнең ачык чагылышы. Кайчан да булса үләчәген аңлаган кеше үзен башкача тота башлаган кебек, дөнья бетәчәген аңлаган кешелек тә үз тормышына җаваплырак карый башлыйдыр. Ләкин сүз бу турыда түгел.

Шулай итеп, әгәр дә микрокосм - макрокосмның кечерәйтелгән копиясе, ә туу белән үлемнең глобаль параллельләре бар икән, кешенең җитлеккән чоры кешелекнең кайсы этабына туры килә?

### МӘҮЛИД – МӨХӘММӘД (с.г.в.)ТУРЫНДА СӨЙЛӘШЕРГӘ ЧАКЫРУ

Бу сорауны без үз-үзебезгә бөтен мөселман дөньясы Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тууын - Мәүлид бәйрәмен билгеләп үткәндә бирәбез. Тантананың төп мәгънәсе - Мөхәммәд (с.г.в.) Пәйгамбәр шәхесен, аның рухи үрнәген искә төшерү, аңа булган ихтирамыбызны белдерү. Гомумән, Пәгамбәребезне (с.г.в.) хөрмәт итү, бигрәк тә Мәүлид бәйрәмендә, ислам мәдәниятенә хас нәрсә. Элек татарлар моны Рәсүлебезне мактаган мөнәҗәтләр һәм касыйдәләр, аның сыйфатлары язылган шәмаилләрнең бер төре булган хильялар аша белдергәннәр. Бүгенге көндә мөселман вәгазьләүчеләре яңа ысуллар кулланалар. Мәсәлән, Америка галиме Майкл Хартның (1978 нче һәм 1992 нче елларда басылган) "Тарихтагы 100 иң абруйлы кеше" китабында Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) беренче урында тора. Көнбатышта яшәүче кеше өчен бик үк гадәти булмаган бу сайлауны автор үзе Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) эшчәнлеге дини өлкәдә дә, дөньяви өлкәдә дә искиткеч уңышлы булган тарихта бердәнбер шәхес дип аңлата, чөнки Мөхәммәд (с.г.в.) бөек дингә нигез салучы да, ышанып булмаслык уңышларга ирешкән сәяси лидер да. Кешелек тарихында башка мондый мисаллар юк.

Бу факт, һичшиксез, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) шәхесен бәяләүче тагын бер сыйфат, ләкин бу аның кешелек тарихына йогынтысын тулысынча ачып бетерә алмый. Мөселманнар Пәйгамбәрнең ролен Коръәни-Кәрим сүзләре аша кабул итәләр: "Мөхәммәд галәйһиссәлам ирләрегезнең һәрберсенең атасы булмады... ул Аллаһының Рәсүле вә пәйгамбәрләрнең ахыргысыдыр". ("Мухаммад не является отцом кого-либо из ваших мужей, а является Посланником Аллаха и печатью пророков...") (Коръән, "Әхзаб" сүрәсе, 40 нчы аять).

### КЕШЕЛЕКНЕҢ БАЛАЧАГЫ ҮТТЕ

«Пәйгамбәрләр мөһере» (печать пророков, хатем, тәмамлаучы) эпитетының берничә мәгънәсе бар. Беренчедән, бу беренче кеше булган Адәмнән (г.с.) башлап килгән пәйгамбәрләр рәте тәмамлануын, мөһер куелуын аңлата. Икенчедән, бу Мөхәммәдкә (с.г.в.) кадәр җибәрелгән пәйгамбәрләрне таный, чөнки рәсми кәгазьгә куелган мөһер язылган текстның дөреслеген аңлата. Өченчедән, мөһер соңгы Пәйгамбәр (с.г.в.) аркылы җибәрелгән бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгалә турындагы тәгълиматның тулылыгын һәм камиллеген белдерә, чөнки мөһер куелгач, үзгәрешләр кертелә алмый.

Ләкин мәкаләнең беренче өлешендә язылган караш масштабында "пәйгамбәрләр мөһере" нәрсәне аңлата соң? Башкача әйткәндә, Мөхәммәднең (с.г.в.) килүен кешелек тарихы барышында нәрсә белән чагыштырып була? Бу сорауга җавап бирер өчен ислам тәгълиматы буенча Аллаһы Тәгалә кешене Җиргә җибәргәч, аны үзен генә калдырмавын, хакыйкатькә һәм эчке гармониягә ирешергә булышуын белергә кирәк. Элек Аллаһы Тәгалә моны һәр халыкка җибәрелгән пәйгамбәрләр аша эшләгән. Ләкин Мөхәммәд (с.г.в.) килү белән пәйгамбәрләр җибәрелү туктый. Бу гомумән тарихи процесс өчен нәрсәне аңлата соң? Билгеле булганча, балачакта һәрберебез олы кеше ярдәменә мохтаҗ. Ләкин вакыт үтү белән без үз тормышыбызны үзебез төзи алырлык була башлыйбыз. Кешелек тә шулай ук. Башта Аллаһы Тәгалә кешелеккә Китаплары, "әйтеп торулары" белән ярдәм итә, үстерә, ләкин билгеле бер вакытта бу булышлык туктый. Мөхәммәднең (с.г.в.) "пәйгамбәрләр мөһере" булуы кешелекнең балачагы бетүен аңлата, хәзер кешелек олылык (балигълык) чорында һәм үз тормышын үзе билгеләргә тиеш. "Пәйгамбәрләр мөһере" кешелекнең гомерен икегә бүлә, мәшәкатьсез балачакның бетүен аңлата.

Мөселманнар Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) үзеннән соң камил дин калдыруына ышаналар. "Минем миңа кадәр килгән пәйгамбәрләргә мөнәсәбәтемне бик шәп итеп төзелгән, ләкин бер ташы гына җитмәгән сарай турындагы хикәя аша аңларга була. Мин буш урынны тутырдым һәм төзелеш тәмамланды", - дип әйткән Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.). Бу фикерне XX гасырның танылган мөселман галиме Мөхәммәт Икбал исламдагы бөек фикер дип атый. Кайбер ригористлар Коръәни-Кәримнең һәм соңгы Пәйгамбәрнең камиллегенең мәгънәсе мөселманнар тормышының өстәмәләр һәм төзәтүләргә мохтаҗ булмавын аңлатуда түгел, ә башкада, дип уйлый. "Пәйгамбәрлек исламда үзенең камиллегенә үзен бетерү кирәклеген табуда ирешә", - дип яза Икбал. Башкача әйткәндә, күрсәтелгән идеянең интеллектуаль кыйммәте бәйсез тәнкыйтьчел мөнәсәбәт ... һәм абруйга ирешкән пәйгамбәрлеккә дәгъва итүче теләсә нинди кешегә юл ябылуына ышануда.

Ләкин күпчелек кеше "пәйгамбәрләр мөһере"ннән соңгы чорда яшәүләрен аңларга, тулы тормыш белән яңа чорда - акыл һәм җаваплылык чорында яшәргә теләмиләр. Аларга гамьсезлек һәм ваемсызлыкта яшәве тынычрак. Икенче яктан, кайсыбыз бәхетле һәм ваемсыз балачагына кайтырга хыялланмый икән?

---

*Ахыры. Башы 2 нче биттә.*

– Әйе, безнең җирлектә 1917 нче елгы инкыйлабка хәтле егермедән артык календарь чыккан һәм аларның барысында да диярлек намаз вакытлары күрсәтелгән. Мисал өчен, Каюм Насыйри, Идрисовлар һәм башкалар чыгарган календарьлар. Аларга күз салсак, барысы да намаз вакытларын астрономик исәпләүгә нигезләнеп төзегән.

**– Ә алайса ястү сәгать ярымнан соң керә дип билгеләү каян кергән?**

– Бу инде дин тыелган чорда, намаз вакытларын астрономик исәпләүгә нигезләнеп төзергә рөхсәт булмаган вакытлары кергән дип уйлыйбыз. Чөнки календарьларга игътибар итсәк, 1918 нче елда намаз вакытларын күрсәтү кими башлый. 1920 нче елда ул бөтенләй бетә. 1924 нче елда Диния нәзарәте аерым календарь чыгара башлый, анда кояш бае һәм чыгу вакытлары гына күрсәтелгән. Ләкин алар аерым бер биттә Советлар Союзындагы зур шәһәрләр өчен ел дәверендә өйлә вакыты күрсәтелгән кушымта чыгара. Анда, икенде вакыты - кояш батарга 1 сәгатьтән укыгыз, иртәнге намазны кояш чыкканчы 1 сәгать 40 минут кала, ястүне ко-яш баеганнан соң - 1 сәгать 30 минуттан соң укыгыз, дип язылган. Билгеле булганча, бу төгәл вакыт түгел. Һәм халкыбыз намазын башкара алсын өчен шул вакытларда әйтелгән тәгълимат дип уйлыйбыз.

**– Ә яңа календарьны ничек төзедегез?**

– Әйтеп китәргә кирәк, бөтен ислам илләрендә намаз вакытлары өчен астрономик исәпләү кулланыла һәм безнең бабаларыбыз да инкыйлабка хәтле шулай исәпләп килгән. Шуңа күрә, без, ягъни Голәмалар шурасы әгъзалары карар кылдык: яңадан инкыйлабка хәтле булган гадәткә кайтырга, намаз вакытларын астрономик исәпләргә таянып төзергә. Ел дәверендә безнең ышанычлы егетләр таң атуны һәм шәфәкъ кызыллыгы бетүен карап килде. Аларның әйтүләренә таянып, башка исәпләү программаларын чагыштырып һәм өйрәнеп, КФУ астрономнарына үзебезнең тәкъмимнәрне әйттек һәм алар безгә намаз вакытларын исәпләп бирделәр.

**– Ә җәй көне шәфәкъ кызыллыгы һәм аклыгы бетмәгәндә ничек исәпләдегез?**

– Әйе, май башыннан алып, август башына хәтле безнең җирлектә шәфәкъ кызыллыгы һәм аклыгы бетми. Борынгы календарьларга карасак, җәй көннәрендә иртәнге һәм ястү намазлары вакыты күрсәтелмәгән, чөнки вакыты керми. Ул вакытта төрле мәхәллә үзенчә бер вакытны билгеләп укыгандыр дип уйлыйбыз. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикерләр әйтте. Һәрберсенә тукталып тормыйм, фәкать үзебез алган фикерне генә яктыртып китәм. Безнең мәшһүр хәнәфи мәзһәбе "Хәшия ибн Габидин" китабында ул вакытта шәфәкъ кызыллыгы бетә торган төбәккә карап билгеләргә диелгән. Әлеге фикерне Галимҗан Баруди "Хөснел-гыйбадәт" китабында дөрес дип саный. Шуңа күрә без ул төбәкнең намаз вакытларын тикшердек һәм аларда бу вакыт сәгать ярым чамасына туры килде. Шуңа таянып җәйге көннәрдә ястү намазын кояш баеганнан соң сәгать ярым узгач укырга ярый, ә сәхәр вакытын кояш чыкканчы ике сәгать дип бил-геләдек.

**– Равил хәзрәт, ахыргы соравыбыз. Моңарчы укып килгән намазларыбыз дөрес буламы?**

– Иншә Аллаһ, дөрес була, чөнки алар Диния нәзарәте тарафыннан төзелгән календарьга таянып башкарылган. Ә яңа календарь чыкканнан соң шушы дөрес календарьны куллану һәрберебезгә дә тиешле. Әгәр берәр сорау туа калса, Голәмалар шурасы әгъзалары аңлатып бирергә әзер. Аллаһ Раббыбыз башкарган намазларыбызны кабуллардан кылсын!

**Әңгәмәдәшләр - Хатыйп ГӘРӘЙ, Нияз САБИРҖАНОВ**



**Бу мәсьәлә буенча өч төрле фикер бар:**

**Җеннәр өчен пәйгамбәрләр җеннәр арасыннан түгел, ә кешеләр арасыннан җибәрелгәннәр. Бу галимнәрнең күпчелегенең фикере һәм аеруча өстенлекле фикер булып исәпләнә** ***(Фәтавас-Субки, 2/618; бине Нуҗейм, әл-Әшбах ван-назаир, 2/330; Тәфсирү Разый, 13/195; бине Хәҗер әл-Хәйтами, әл-Фәтавал-хәдисия, 69 нчы бит).***

**Җеннәрдән пәйгамбәрләр булмаган, ә алар арасында пәйгамбәрләрдән гыйлем алып, аннан соң башка җеннәрне дингә үгетләгән "нөзүр" дип аталучы җеннәр булган. Бине Габ-бас (р.г.), Мөҗәһид, бине Җурейҗ һәм Әбу Убейда шундый фикердә булганнар** ***(Тәфсирүт-Табари, 26/31; Фәтвас-Субки, 2/618).***

**Җеннәргә җеннәрнең үзләреннән пәйгамбәрләр җибәрелгән булган. Имам Мөҗәһид, Даххак һәм бине Хазм әл-Әндәлүси шундый фикердә булганнар** ***(Тәфсирел-Куртуби, 7/86; Тәфсирел-Әлүси, 8/28; Тәфсирур-Рази, 13/195).***

# ҖЕННӘР АРАСЫНДА ПӘЙГАМБӘРЛӘР БАРМЫ?

Ә хәзер бу һәр өч фикер вәкилләренең дәлилләренә җентекләп туктап китәргә телибез.

Алда әйтеп кителгәнчә, галимнәрнең күп өлеше беренче фикер тарафдарлары булган. Имам Субки болай дигән: *"Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) Аллаһ диненә өндәү өчен кешеләргә һәм җеннәргә берьюлы җибәрелгән һәм мин бу җәһәттән башка төрле фикерне белмим. Галимнәр бу мәсьәлә буенча шундый ук фикердә"* ***(Фәтвас-Субки, 2/594).***

Бине Нуҗейм дә шулай ук: *"Галимнәрнең күпчелеге җеннәр арасында пәйгамбәрләр булмаган дигән фикердә",* - дип исәпли ***(бине Нуҗейм, әл-Әшбах ван-Назаир, 2/330).***

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә болай ди:

**"Синнән элек җибәргән пәйгамбәрләребез дә үз шәһәрләреннән ирләрдер. Без аларга аятьләребезне вәхи кыладыр идек. Югыйсә фәрештә түгел иделәр. Әйә алар җир өстендә сәяхәт кылып йөрмиләрме? Әгәр йөрсәләр, күрер иделәр әүвәлге каферләрнең ахыры ничек булганын. Иман китереп, Аллаһка тәкъвалык кылган кешеләргә ахирәт йорты хәерледер, әйә шуны аңлый алмыйсызмы?"** ***("Йосыф" сүрәсе, 109 нчы аять).***

Имам Куртуби бу аятьнең тәфсирендә: *"Бу аятьнең эчтәлегеннән без хатын-кызлар, фәрештәләр һәм җеннәр арасыннан пәйгамбәрләр булмаганын күрә алабыз",* - дип билгеләп китә. ***(Тәфсирел-Куртуби, 9/274).***

Коръәндә шулай ук мондый юллар да бар:

**"Синнән әүвәл җибәрмәдек рәсүлләрдән мәгәр кешеләрдән рәсүл итеп җибәрдек, алар ашыйлар вә базарларда йөриләр иде. Бәгъзегезне бәгъзегезгә фетнә кылдык, байны фәкыйрьгә, сәламәтне сырхаулыга, дәрәҗәлене дәрәҗәсезгә, әйтер: мин ник аның кеби булмадым дип. Ий мөэминнәр, хәлегезне сабыр итәсезме, Раббың хәлегезне күрүче булды, сабыр итсәгез, әҗерен бирер"** ***("Фуркан (Аеручы)" сүрәсе, 20 нче аять).***

Күпчелекнең фикере буенча, бу ике аять Аллаһы Тәгаләнең җеннәрдән пәйгамбәрләр җибәрмәвенә ачык дәлил.

Хәзер инде, җеннәрдән пәйгамбәрләр булмаган, алар арасында кешеләрдән булган пәйгамбәрләрдән тиешле гыйлемнәр алып, дингә өндәүчеләр булган, дип исәпләүче галимнәрнең позициясен карап китик. Аларның фикере буенча, бар пәйгамбәрләр дә кешеләр булганнар, тик Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте белән, хак юлны аңлап, башка җеннәрне дингә өндәгән тәкъва җеннәр дә булган.

Бине Габбас (р.г.) болай дигән: *"Җеннәрнең илчеләре, Изге Коръәндә бу турыда әйтелгәнчә, үз ишеткәннәрен үз кавемнәренә җиткергәннәр:*

**"Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам, шул хәлне зикер ит ки, сәхабәләрең илә иртәнге намазны укыган вакытыңда Коръән сүзләрен ишетсеннәр өчен, бер төркем җеннәрне сиңа очраттык, Мөхәммәд галәйһиссәлам янына якын килгәч, бер-берсенә әйттеләр: "Сөйләшмичә Коръәнне тыңлап тик торыгыз", – дип. Коръән укылып беткәч, кавемнәренә кайттылар, ишеткән Коръәннәре белән аларны куркытучы булганнары хәлдә"** ***("Әхкаф (Комлык)" сүрәсе, 29 нчы аять), (Тәфсирел-Куртуби, 7/86).***

Мөҗәһид фикере буенча: *«Җеннәрдән рәсүлләр юк. Бар рәсүлләр дә кешеләр булганнар. Ә җеннәр арасында дингә өндәүчеләр рәсүлләрнең илчеләре булып торганнар. Шуңа күрә дә без кешеләр арасыннан булган рәсүлләрне "рәсүлләр" дибез, ә җеннәрнең илчеләрен – "нөзүлләр" (искәртүчеләр)* ***(Бине Әбу Хатим, № 7903,4/1389).***

Бине Җурейҗ һәм Әбу Убейда да: *"Гәрчә җеннәр арасында илчеләр булса да, алар рәсүлләрнең илчеләре булганнар",* - дигән шундый ук фикердә торганнар.

Җеннәрнең пәйгамбәрләре җеннәр үзләре булган, дигән фикернең төп тарафдары булып Даххак исәпләнә. Ул: "Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) җибәрелгәнгә кадәр, җеннәрдән пәйгамбәрләр булганмы?" - дигән сорауга Аллаһ Рәсүленең (с.г.в.) шундый аять укыганлыгы турында хәдис китерә:

**"Ий җен вә кеше Таифәләре! Сезгә безнең аятьләребезне укучы һәм менә шушы куркынычлы көнегезгә юлыгачагыгыз белән куркытучы рәсүлләр үз җенесегездән килмәдеме? Динсезләр әйтерләр: "Бәлки бүген без үз зарарыбызга шәһадәт бирәбез", - дип, аларны дөнья тереклеге алдады һәм кафер икәнлекләре белән шәһадәт бирделәр".** ***("Әнгам (Терлек)" сүрәсе, 130 нчы аять).***

Һәм аннан соң ул шулай дигән: *"Әллә син Аллаһы Тәгаләнең Үзенең бу ачышын ишетмәдеңме? Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә үзе әйткәнчә, рәсүлләр кешеләр арасында да, җеннәр арасында да булган"* ***(Тәфсируд-Даххак ,1/353; Тәфсирут-Табери, № 13899, 5/345).***

Имам Мукатил: *"Аллаһ җеннәргә җеннәрдән, ә кешеләргә кешеләрдән рәсүлләр җибәргән", - дип исәпләгән.*

Ул Коръәннән шундый аятьләр китергән: **"Җирдәге төрле хайваннар һәм ике канатлары белән оча торган кошлар сезнең кеби җәмәгать булудан башка нәрсә түгелләр. Ягъни үз җенесләре белән җәмәгать булып яшиләр, һәрбере үз хәлләре белән мәшгульләр һәм Аллаһны да зикер итәләр. Ләүхелмәх-фуздагы китапта язмыйча һичнәрсәне калдырмадык, соңра һәр мәхлук кубарылып Раббыларына кайтырлар"** ***("Әнгам (Терлек)" сүрәсе, 38 нче аять).***

Һәм шулай ук: **"Тәхкыйк Без сине хаклык вә Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәрне җәннәт белән сөендерүче вә Коръән белән гамәл кылмаучылырны җәһәннәм белән куркытучы итеп җибәрдек. Дөньяда нинди генә кавем яшәсә дә, аларны Аллаһ газабы белән куркытучы пәйгамбәр булды"** ***("Мәләикә (Фәрештәләр)" сүрәсе, 24 нче аять).***

Шул аятьләргә нигезләнеп ул, Раббының яратканнары арасында Аллаһы Тәгалә хакыйкатен аңлатучысыз калган бер генә төре дә булмас, ди. Үз позициясенең хаклыгын дәлилләү өчен тагын шундый аять китерә: **"Әйт: "Әгәр җирдә яши торган затлар – кешеләр урынында фәрештәләр булса иде, әлбәттә, ул вакытта аларга пәйгамбәр итеп күктән бер фәрештә җибәрер идек"** ***("Бәни Исраил (Ягъкуб балалары)" сүрәсе, 95 нче аять).***

Шулай булгач җеннәр кебек аңлы затлар аңлый һәм кабул итә торган пәйгамбәрне үз араларыннан җибәрү аңлашыла торган күренеш һәм бик табигый булган булыр иде, ә алар - Адәм (г.с.) яратылганчы ук яра-тылган затлар. Фәрештәләр өчен дингә өндәүчеләр — фәрештәләрдән Җәбраил (г.с.) белән Микаил (г.с.), кешеләр өчен дингә өндәүчеләр — кешеләр арасыннан сайлап алынган Нух, Ибраһим, Муса, Гайса һәм Мөхәммәд (салаватуллаһи әля нәбиийнә вә галәйһем әҗмәгыйн) пәйгамбәрләр булганлыктан, җеннәр өчен дә җеннәр арасыннан пәйгамбәрләр булуы – бик закончалыклы күренеш булып исәпләнә.

Бу мәсьәлә буенча бар фикер каршылыклары да Мөхәммәд Пәйгамбәргә (с.г.в.) кадәрге чорга карыйлар. Ә Аллаһ Рәсүленең (с.г.в.) кешеләргә дә, җеннәргә дә җибәрелгән Рәсүл булуында беркемнең дә бернинди дә шикләре юк ***(Галәмел-җен, Габдел-Кәрим Нафзан, 210 нчы бит).***

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ИЛЧЕСЕ (с.г.в.) ҖЕННӘР ӨЧЕН ДӘ ПӘЙГАМБӘР БУЛГАНМЫ?

Пәйгамбәребез (с.г.в.), киң таралган фикер буенча кешеләр өчен дә, җеннәр өчен дә пәйгамбәр.

Имам Шибли "Акакмуль-мәрҗән фи әхкамил-җән" хезмәтендә Аллаһы Тәгалә Илчесенең (с.г.в.) кешеләр өчен дә, җеннәр өчен дә пәйгамбәр булуында бер мәзһәбтә дә шик һәм каршылыклар юк икәнлеге турында яза.

Күпчелек галимнәр кебек үк Ибни Габдилбәрр һәм Ибни Хәзм Аллаһы Тәгалә Илчесенең (с.г.в.) кешеләр өчен дә, җеннәр өчен дә пәйгамбәр булуын ассызыклыйлар.

Имамуль-Хәрамәйн Әл-Җувайни "Әл-Иршад" хезмәтендә: "Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) үзенең кешеләр өчен дә, җеннәр өчен дә җибәрелүен ачык әйтүе билгеле", - дип яза.

Хәдисләрдә, Коръәни-Кәримнең кайбер аятьләрендә дә моңа ачык дәлилләр бар: **"Коръән тыңласыннар дип бер төркем җенне синең янга җибәрдек. Коръән тыңларга әзерләнеп беткәч, алар бер-берсенә әйтте: "Тынычыз!** ***(Тын да алмыйча тыңлагыз!)",-*** **диделәр. Коръән укылып беткәч, алар** ***(Кыямәт көнне булачак җәзалар турында)*** **кисәтүче булып, үз кавемнәренә әйләнеп кайтты. Алар: "Әй, кавемебез, хак сөйлибез: без Мусадан соң иңдерелгән һәм үзеннән алда килгән** ***(бозылган китапларны)*** **дөресләүче, Хакыйкатькә вә тугры юлга юнәлтүче бер китап сүзен тыңладык. Әй, кардәшләребез! Аллаһның кисәтүчесенә буйсыныгыз. Аллаһка иман китерегез. Һәм Аллаһ сезнең бер өлеш гөнаһларыгызны кичерер вә сезне әче газаптан коткарыр", - диделәр. Аллаһның кисәтүчесенә колак салмаган кеше Аллаһны Җир йөзендә бичара хәлдә калдыра алмас. Аллаһтан башка ул кеше үзенә дуслар да табалмас. Менә шулар инде күрәләтә юлдан язган бәндәләр"** ***("Әхкаф" сүрәсе, 29-32 нче аятьләр).***

**"*(Ий, Мөхәммәд)* әйт син: "Җеннәр кавеменең бер төркеме *(мин Коръән укыганда)* тыңлап, иман китергән икән. Бу турыда мин вәхи аша белдем", - диген. Җен кавеменнән булганнарның бер төркеме болай дигән: "Чыннан да, без тугры юлга өнди торган, гадәттән тыш гүзәл Коръән сүзләрен тыңладык һәм иман китердек"** ***("Җен" сүрәсе, 1-2 нче аятьләр).***

"Әр-Рахмән" сүрәсендә Аллаһы Тәгалә кешеләргә һәм җеннәргә мөрәҗәгать итеп, берничә тапкыр сорый: "**Шулай булгач, Раббының нигъмәтләреннән кайсын ялганга чыгарыр идегез?»** ***("Әр-Рахмән" сүрәсе, 16 нчы аять).*** Җәбир (Аллаһ аннан разый булсын) әйтүе буенча Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхабәләре янына чыга һәм "Әр-Рахмән" сүрәсен тулысынча укый. Сәхабәләр сөйләшмичә тыңлап торалар. Ахырда болай ди: "Җеннәр төнендә мин бу сүрәне җеннәргә укыдым, алар сездән яхшырак җавап бирделәр. Мин **"Шулай булгач, Раббының нигъмәтләреннән кайсысын ялганга чыгарыр идегез?"** аятен укыган саен, алар: "Раббыбыз! Без Синең шәфкатьләреңнең берсен дә кире какмыйбыз, Сиңа гына мәдхия укыйбыз!" - дип җавап бирделәр". ***(Тирмизи, 55 тәфсир, № 3291, 5/399.)***

Әбу Һурайра (Аллаһ аннан разый булсын) тапшыруы буенча Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: "Мин барлык тереклек иясе өчен дә җибәрелгән". ***(Мөслим, Мәсәҗид: 1, №1195, 2/64; Тирмизи, Сияр: 5, №1533)***

***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***



Галимҗан БАРУДИ

# Мәүлидүн-Нәби бәйрәме хакында бер-ике сүз

Элекке заманнарда Пәйгамбәребез Мөхәммәд Рәсүлуллаһ (с.г.в.) хәзрәтләренең туган көнен аермачык билгеләп бәйрәм итү һәм шул көндә фәкыйрь-мескеннәрне ашлар ашатып, аларны сәдакалар биреп шатландыру, Рәсүлуллаһның (с.г.в.) туувы, үсүе хакында гарәп яки төрки телләрдә бәян ителгән касыйдәләрнең укылганы төгәл билгеле түгел.

Әмма һиҗри исәп белән VI гасырда Әрбил падишаһы **Мәлик Мозаффар Әбу Сәгыйть Күкбүре бине Гали бине Биктәгин** *(ул беренчеләрдән булып 1207 нче елда Мәүлидне бәйрәм буларак оештырган)* Мөхәммәд Рәсүлуллаһны (с.г.в.) ихлас күңеленнән яратканга һәм үзе дә бик юмарт кеше булганга, шушы "Мәүлид-шәриф касыйдәсе"н укуны һәм зур табыннар – ашлар әзерләп, халыкны җыеп ашатуны, шунда күп изгелек кылып, сәдакалар таратып, кешеләргә ярдәм итүләрне гадәткә кертә. Ул һәр ел саен "Мәүлид-шәриф" көнендә галимнәрне, мәшәехләрне һәм дә күп санлы фәкыйрьләрне җыеп зур аш мәҗлесе ясый. "Мәүлид-шәриф" касыйдәләрен укучыларга һәм голәма, мәшәехләргә яхшы, матур киемнәр бүләк итеп, якынча өч йөз мең алтын микъдарында мал сарыф итә. Рәсүлуллаһны (с.г.в.) бик тә яратканга күрә күңеле тулып, аның өммәтен, бихисап фәкыйрьләрне һәм гыйлем әһелләрен, бу "Мәүлид-шәриф" бәйрәме сылтавы белән, шулкадәр күп маллар сарыф итеп шатландыра торган була.

Хафиз ибне Рәҗәп "Ләтаифүл – мәгариф" исемле китабында дүшәмбе көн ураза тотуның мөстәхәб булуы хакында хәдисшәриф бәян итеп, "Мәүлид-шәриф бәйрәме"нә һәм анда, ачык рәвештә халыкка белдерел, шөкраналар кылырга кирәклегенә дәлилләр булганлыгын күрсәтә. Хәдисләр җыентыгы "Мөслим"дә, Әбу Котада радыйаллаһу ганһүнең риваять итүенчә, Рәсүлуллаһтан (с.г.в.) аның дүшәмбе көнне ни өчен ураза тотуы турында сорагач: *"Зәликә йәүмун ву-лидту вә унзилэт галәйә фиһи ән нубувәтә!"* – дип әйткән. Тәрҗемәсе: *"Бу көнне мин туганмын һәм миңа пәйгамбәрлек иңдерелгән!"*

Димәк, бу Рәсүлуллаһ (с.г.в.) үзенең туган көнен һәм пәйгамбәрлек килгән көнен аерым гыйбадәт белән хөрмәт итүе, шушы олы нигъмәт өчен *(кешеләргә сөекле пәйгамбәрен җибәргәне өчен)* мөселманнарның Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылырга тиешлеген күрсәтә. Шуңа күрә, ай хисабы буенча да аның туган көнен, шәригать кысаларыннан чыкмыйча, нинди рәвештә булса да хөрмәт итү нигезсез түгел, ә киресенчә, дөрес икәнлеге исбатлана.

Телгә алынган Хафиз ибне Рәҗәпнең "Ләтаифүл – мәгариф"ендә, "Мөслим"дә Әбу Котада радыйаллаһу ганһүнең риваяте буенча, китерелгән хәдисләргә таянып исбат ителгәннән соң, шулай ук мөхәддис, фәкыйһ галимнәрне дә искә алып үтмичә булмас. Сөюти, Гаскалани вә Касталани хәзрәтләренең дә, бу мәсьәләдә хәдис-шәрифләр китереп, Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәламнең туган көнен ихтирам итүне, рөхсәтле һәм күркәм эш икәнлегенә фәтва биргәннәрен дә күрә алабыз. Боларны төгәл итеп белергә теләгән кешеләр шәех Йосыф бине Исмәгыйль Нәбаһәнинең "Хуҗҗәтуллаһи галәл галәмин фи мугъҗизәт сәйидиль мурсәлин" китабына мөрәҗәгать итә ала!

*Вәффәканә-ллаһу вә иййәкум бимә фиһи ридаһу!*

*(Аллаһ безгә һәм сезгә Аның ризалыгын алырга ярдәм итсен!)*

***Галимҗан хәзрәт Әл-Барудиның «Әд-дин вә әл-әдәб» журналыннан алынды***

# Йосыф АКЧУРА:

## «БАРУДИНЫҢ БАР ТОРМЫШЫ ИКЕ ПРИНЦИПТА ҮТТЕ»

**Галимҗан Баруди - XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында яшәгән күренекле татар дин галиме һәм мәгърифәтчесе. Без бу мәкаләдә Барудиның күпкырлы эшчәнлегенең кайбер якларын гына карап китәрбез. Ул – үз вакытының иң яхшы мөселман уку йортларының берсе "Мөхәммәдия"гә нигез салучы, беренче Бөтенроссия мөселман фиркасы "Иттифак әл-мөслимин"нең лидеры, 1917 нче елдан 1921 нче елга кадәр – мөфти. Галимҗан Баруди ислам идеаллары өчен хезмәт иткән, татар халкының дини һәм милли үзаңын торгызуда бик күп көч салган шәхес.**

Галимҗан Галиев (Баруди) 1857 нче елның 2 нче февралендә Казан өязенең Кече Кавал авылында (Татарстанның Биектау районы) туган. Кечкенәдән үк бик кызыксынучан, сәләтле бала була. 1862 нче елны аны "Касыймия" мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул әлеге мәдрәсәнең башлангыч, урта һәм югары баскычларын үтә, бер үк вакытта югары сыйныфларда мөгаллимлек эше белән дә шөгыльләнә.

Үсмер елларында ук ул тормыш мәгънәсе, җәмгыять һәм кешенең җәмгыятьтәге роле турында уйлана башлый. Мәдрәсәдә укыганда үзлегеннән гыйлемен арттыра, күп укый һәм укыганнары турында уйланырга ярата торган була. Аның турында Йосыф Акчура: "Барудиның бар тормышы ике принципта үтте – укырга һәм укытырга", - дип яза.

1875 нче елның мартында Г.Баруди Бохарада белемен дәвам итәргә була. Анда ул дини предметларны һәм шәригатьне өйрәнә, алардан тыш, арифметикага аерым игътибар бирә.

Ләкин Бохарадагы укыту процессыннан Барудиның күңеле кайта, чөнки алар берниндн программасы һәм расписаниесез алып барыла. 1882 нче елда ул Казанга кире кайта, аны Казанның Зур таш мәчетенең (Ак мәчетнең) икенче имамы итеп билгелиләр. Шул көннән башлап ул бер-ике шәкерткә дәресләр бирә башлый, шәкертләренең саны әкренләп арта бара.

1883 нче елда ул атаклы татар сәүдәгәре И.Үтәмешовның кызы Бибимаһруйга өйләнә. Бик яхшы белем алган бу кыз Барудиның рухи омтылышлары һәм кызыксынуларын тирәнтен аңлаучы, лаеклы тормыш иптәше була, мәхәллә мәчете каршындагы кызлар мәктәбен җитәкли, мәгърифәт эшчәнлегендә иренә ярдәм итә.

Шул ук елны әтисе Мөхәммәтҗан Галиевның ярдәме белән Галимҗан Баруди мәдрәсә оештыра, ул мәдрәсә аңа нигез салучының исеме белән "Мөхәммәдия" дип атала. Соңыннан бу мәдрәсә Россиянең иң яхшы мөселман уку йортларының берсенә әйләнә. Яңа мәдрәсәдә Г.Барудин чын мәгариф реформасы үткәрә, ул уку курсына бик күп яңа предметлар кертә, бу уку йортында рус теле, арифметика, геометрия, хисап, рәсем, этика, гигиена һәм башка дөньяви предметлар укытыла башлый. Моның өчен махсус укыту әсбаплары булмау сәбәпле, Г.Баруди дәреслекләрне үзе эшли, аларның күбесе соңыннан мәктәп уку кулланмаларының классик үрнәге булып китә һәм дистәләрчә тапкыр бастырып чыгарыла. Шулар исәбеннән төрек теленең яңа ысуллы беренче әлифбасы, арифметика, гарәп теле буенча дәреслекләр, татарча-гарәпчә-фарсыча сүзлек һәм башка бик күпләрне күрсәтергә була.

XX гасыр башында "Мөхәммәдия"дә укыган шәкертләрнең саны 500 гә җитә, аларга егерме мөгаллим белем бирә. Бу мәдрәсәдә татар интеллигенциясенең йөзек кашлары белем алган. Барудиның эшчәнлеге мөселман мәктәбен бик тиз арада тәрәккыят юлына алып керә һәм белем алу процессын халыкның рухи яңарышының төп инструментына әйләндерә.

Галимҗан Баруди татарлар арасында иң абруйлы һәм иң йогынтылы шәех – Зәйнулла Рәсүлев белән якынлаша. Ул вакытларда аның замандашлары Рәсүлевны "татарның короле" дип атап йөртәләр, Баруди аның мөриде булып китә.

Гаспринский "Шәехлек һәм шәехләр" мәкаләсендә болай дип яза: "Зәйнулла хәзрәт һәм Галимҗан Барудилар ... чынлап торып та безне шатландыралар, алар халык тормышы мәнфәгатьләренә, аның дини-әхлакый пакьләнүенә хезмәт итәләр". Рәсүлев "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә аеруча зур игътибар күрсәтә, андагы эш торышы һәм хәлфәләренең хәле турында Барудидан гел белешеп тора. Мәдрәсәдә бер булуында шундый нотык тота: "Мәгариф реформасы өлкәсендә бергәләп иҗтиһад кылыгыз (тырышлык күрсәтегез), шул юлда хезмәт итегез, үзара дошманлашмагыз, милли һәм дини эшләрдә тарткалашмагыз, мин сезгә үземнең хәер-фатихамны бирәм".

Зәйнулла ишан Рәсүлев Галимҗан Барудига үз шәкертләре исәбеннән үз мөридләрен булдырырга хокук (иҗазәт) бирә. Моны мәгърифәтчеләр һәм шәкертләр төрлечә кабул итәләр. Шул вакытларда шәкертләр арасында аның турында "Әй шәехем Галимҗан" шигыре барлыкка килә.

Ул Зәйнулла ишанның гади бер мөриде генә булмаган, ә Халидийә-Нәкшбәндийә тарикатендә бу шәехнең егәрле һәм инициативалы варисы да булган. Баруди суфыйчылыкны дини хисләр чагылыш алуының бик мөһим бер төре, ул философларча фикерләүгә ярдәм итә дип исәпләгән, суфыйчылык законнар һәм инанулар белән аңлап булмый торган хакыйкатьне аңларга булыша дип билгеләп киткән.

1906 нчы елның гыйнварында Галимҗан Баруди "Дин вә әдәп" дигән фәнни-дини һәм әдәби журнал чыгара башлый, бу журнал битләрендә педагогик һәм дини характердагы идеяләр тикшерелә.

Мәгърифәтче үзенең журналы битләрендә дин белән фәннең якынлыгын күрсәтергә тели. Баруди фикеренчә, фән дингә хезмәт итәргә тиеш, ә дин – фәнгә. Аныңча, тәрбиянең төп максаты – динле, югары әхлаклы кеше, җәмгыятьнең халык һәм гомумкешелек мәнфәгатьләре белән яши торган файдалы әгъзасын тәрбияләү. Татар галименең педагогик карашларында дини-әхлакый тәрбия төп урынны алып тора һәм ул акыл һәм хезмәт тәрбиясе белән тыгыз бәйләнгән.

Баруди ул вакыт мәдрәсә һәм мәктәпләрендә хакимлек иткән ятлау практикасын һәм схоластиканы кискен тәнкыйть итә. Аның фикере буенча, бары тик аңлы рәвештә белем алу гына үз җимешләрен бирергә һәм интеллектуаль үсештә кешене яңа баскычка күтәрергә сәләтле. Ул бар кешеләрнең – шәһәр халкының да, авыл кешеләренең дә белем белән мәгърифәткә ирешә алуларына омтыла.

Галимҗан Барудиның халык өчен шәхси китап коллекциясен ачу турында да әйтеп китәргә кирәк. 1913 нче елда мәгърифәтченең шәхси китап коллекциясендә фәннең төрле өлкәләре буенча өч меңнән артык том китап һәм журнал була. Ислам фикер ияләре һәм дин эшлеклеләренең хезмәтләре китапханәдә алар язган телдә дә, комментарийлар язылган тәрҗемәләрендә дә саклана. Ә 1920 нче елда Баруди үзенең шәхси китапханәсен яшь Татарстан Республикасына бүләк итә, бу вакытта китапханәдә 4288 том китап һәм журнал була.

Галим 1921 нче елда Мәскәүдә вафат була, ул үз тормышының соңгы айларын Идел-Урал регионында таралган ачлык белән көрәшкә багышлый.

Үз халкына фидакарь хезмәт иткән зирәк педагог, суфыйчылык остазы, дин галиме Галимҗан Барудиның якты истәлеге халык хәтерендә саклана.

**Искәндәр НӘБИУЛЛИН,**
**«Ислам" журналыннан**

**Ул көнне Гаилә мәчетенең зур залы аллы-гөлле чәчкәләр үскән болынны хәтерләтә иде. Яшел келәмгә сибелешкән балалар кышкы лагерь ябылышы тантанасына әти-әниләрен дә алып килгәннәр икән. Моннан берничә ел элек япа-ялан кырга күрсәтеп: “Менә шушы урында мәчет булачак”, - дигән Хатип абый Бикмөхәммәтовның оптимистлыгына шаккаткан идем. Ничек башкарып чыгарлар да, йөрүче булмыйча, мәчет буш тормас микән, дип шикләндем. Азинода мөселман гаиләләре аз иде әле ул чакта. Менә бит, Алланың рәхмәте дими ни дисең инде моны – зал тулы халык. Алар арасында күренекле дин әһелләре, шәһәр хакимияте хезмәткәрләре белән бергә татар зыялыларын да күрү мине аеруча сөендерде.**

# «БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ИШЕТӘ БАШЛАДЫК»

Гаилә мәчетенә быелгы кышкы лагерьга 80 ләп бала йөреп, ислам нигезләре буенча гыйлем алган. Мөфти урынбасары, мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин тырышып укыганнары өчен аларның барысына да Мактау кәгазьләре тапшырды. Тантанада катнашкан Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин каникул көннәрен шундый файдалы эшкә – ислам дине нигезләрен, милләтебезнең традицияләрен өйрәнүгә багышлаулары өчен балаларга рәхмәт әйтте; мәктәпне тәмамлагач, дин гыйлемен тагын да тирәнрәк үзләштерер өчен үзләренә укырга килергә чакырды. Мөфти урынбасары, Сукырларны һәм начар күрүчеләрне тернәкләндерү үзәге җитәкчесе Илдар Баязитов исә Гаилә мәчетенең күркәм эшләренә соклануын белдерде.

– Чыннан да, искитмәле эшләр башкарыла безнең мәчеттә, - дип сөйләп алды янәшәмдә утыручы мөлаем ханым Зөлфия Сарманова. – Бу мәчет ачылуга бик сөенәбез. Безнең гаиләдә шулай гадәткә кергән инде – әтиләре җомга намазыннан кайткач, анда ишеткәннәре буенча безне дә вәгазьли. Әмма биредә үз ишләре белән бергәләп шөгыльләнгәндә хәзрәтләрнең сүзләре бала күңеленә ныграк сеңә икән, дигән нәтиҗәгә килдек без. Кышкы лагерьга кызыбыз Алинә канатланып йөрде. Менә кечкенәсе дә бераз үсә төшкәч, мәчеткә дүртәүләп йөри башларбыз әле. Шушы юлга басуыбызга сөенеп тә бетә алмыйм. Үзе диндә булган кеше аңлый инде аны - күңелләребезгә тынычлык инде, үзара мөгамәләләр үзгәрде, без бер-беребезне ишетә башладык...

Алга таба да бөтен мәхәлләбез белән бер гаиләдәй бер-беребезне аңлап, ишетеп яшәргә насыйп булса иде.

**Мәрьямбану ХАФИЗ**



# ГЫЙЛЕМНЕҢ ДӘВАМЛЫ БУЛГАНЫ ХӘЕРЛЕ

**Узган елның декабрь аенда Казан шәһәрендә Идел буе федераль округына кергән авыл-шәһәрләр имамнарының дини белемнәрен күтәрү курслары оештырылган иде. Әлеге курсларның дүртенче төркемендә Татарстанның Теләче, Сарман районнарыннан һәм Удмуртиядән килгән имамнар белем алды.**

Әлеге курслар – Россия тарихында моңарчы булмаган күренеш. Аны оештыруда Идел буе Федераль округы җитәкчелеге, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия ислам институты күп көч куйган.

Мин үзем 2008 нче елда читтән торып “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен тәмамлаган идем. Аңа инде биш ел вакыт үткән, нәрсәдер онытыла да башлаган. Үзем өчен бу курслар алган белеемнәрне яңарту, белмәгәннәрне өйрәнү өчен менә дигән форсат булды. Әле бит безнең арада исламны үзлегеннән өйрәнгән өлкән яшьтәге имамнар да бар, бу курсларның алар өчен әһәмияте аеруча зур. Фикыһ, тәҗвид фәннәрен бик көчле укыттылар, имам вазыйфалары һәм гакыйдә фәннәренең укытылу дәрә-җәсеннән дә канәгать калдык. Исламда секталар, татарларда дин тарихы, риторика фәннәреннән дә шактый мәгълүмат алдык. Риторика, ораторлык осталыгы безгә кадәрге курсларда бөтенләй укытылмаган икән. Халык алдында чыгыш ясау осталыгы имамнар өчен бик тә кирәк. Ләкин безгә дә бу сабак бик аз эләкте. Киләсе төркемнәргә чынлап торып керә башласын иде ул.

Курсларны оештыручыларга тагын бер теләгем бар. Мәгълүм ки, 10 көн бик аз вакыт. Фикыһ, имам вазыйфалары, гакыйдә фәннәренең без, әлбәттә, төп темаларын гына өйрәнергә өлгердек. Әгәр тагын курсларга чакырсалар, калган урыннан дәвам итү иң дөресе булыр дип уйлыйм. Имам вазыйфаларын районыбызга килеп укытып бетерсәләр, бигрәк тә яхшы булыр иде. Тагын безне шатландырганы шул – мәчетләребездә уңышлы эшләп килүче имамнарыбыз Нияз хәзрәт Сабиров, Рөстәм хәзрәт Вәлиуллиннар берничә тапкыр эчтәлекле вәгазь-әңгәмәләр үткәрделәр, Аллаһның рәхмәте булсын аларга.

Россия Ислам институтында булып узган түгәрәк өстәлне дә телгә аласым килә. Анда “Традицион һәм традицион булмаган ислам, хәзерге заманда имамнарның эшчәнлеге” дигән темага сөйләшү булды. Минемчә, бу түгәрәк өстәл бик нәтиҗәле үтте. Иң баштан “традицион ислам” термины турында кайнар бәхәс купты. Мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм Батров, әлеге термин Мөхәммәд (с.г.в.) өйрәтеп калдырган дөрес ислам, дигәнне аңлата, дип төпле аңлатма бирде. Алга таба кайбер имамнарыбыз үзләренең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Укуларыбыз тәмам булгач, мөгаллимнәр һәм дәүләт вәкилләре безгә курсларны тәгәлләвебезне аңлатучы сертификат тапшырды. Белем күтәрү курслары турында барлык имамнар да уңай фикердә калды. Бу эш дәвамлы булса иде, имамнар белемле булганда гына ислам дине үсеше дөрес юнәлештә барачак.

**Раил ИЛЬЯСОВ,**
**Теләче районы**

# *Илдар БАЯЗИТОВ:*

# «ИМАМНАРГА БАШКАЛАРГА КАРАГАНДА ИКЕ-ӨЧ ТАПКЫР ЯХШЫРАК БУЛЫРГА КИРӘК»

Хәзерге заманда имам мәчеттә гыйбадәт кылу вакытын күзәтүче һәм шартларын тудыручы администратор гына түгел. Бу эш белән имамнар беркайчан шөгыльләнмәгәннәр дә. Татар халкының тарихына күз салсак, мәчетләр өммәтнең тормыш үзәге, ә имамнар җитәкчеләр булганнар. Кызганыч, бүгенге көнгә кадәр бу гореф-гадәт сакланып калмаган, һәм мәчеткә йөрүчеләрнең күпчелеге мөселманнарның элек ничек яшәвен һәм мәхәлләнең нәрсә икәнен белми.

Бүген кешеләргә бездә элек мәхәллә системасы булуын, мәхәлләнең ничек яшәвен бары тик имамнар гына җиткерә ала. Әлбәттә, тарихчылар бу турыда гыйльми хезмәтләр язалар, ләкин имамнар төрле кешеләр белән турыдан-туры аралашучылар. Мөселманнар җомга намазларына, башка намазларга килә-ләр, һәм вәгазь вакытында имамнар аларга татар халкының ислам тарихы турында сөйли алалар. Дин тотучылардан кала, мәчеткә еш кына “этник мөселманнар” дип аталучылар да төрле сораулар белән килә, һәм имамнар алар арасында да бу юнәлеш буенча эш алып барырга тиеш. Моннан тыш, минемчә, имамнарга мәчеттән чыгып, мәктәпләргә, оешмаларга барырга, халык белән очрашулар уздырырга кирәк.

***Татарларда исламның иҗтимагый тарихы***

Әлбәттә, мондый аң-белем тарату эшен алып барыр өчен имамнар үзләре дә белемле булырга тиеш. Дини белем бирү йортларында татарларда ислам тарихы турында гына түгел, ә татар исламының иҗтимагый тарихы, мәхәллә тормышы, мәчетләрнең җәмгыять тормышына булган йогынтысы турында җентекләп сөйләргә кирәк. Әлбәттә, XXI гасыр XIX гасыр түгел, ләкин татар исламының мондый иҗтимагый тарихы җәмгыять тормышын ничек төзергә кирәк икәнен күрсәтүче гамәли фән була алыр иде.

Әгәр дә имам авыл җирендә яки Казанның тарихи мәчетендә эшли икән, аңа бу җирлекнең яки мәчетнең тарихын өйрәнергә, кешеләргә бу авылда, мәчеттә мөселманнар тормышының элек нинди булуын сөйләргә кирәк. Кешеләргә, гомумән, локаль тарих – алар яшәгән җирлекнең тарихы кызыграк, шуңа күрә бу тарихны өйрәнеп кенә, кешеләр мәхәлләләрне торгызуның мөһим эш булуын аңлый алалар. Шушы максатны куеп, мәчетләрдә әлеге җирлектәге ислам тарихын өйрәнүче түгәрәкләрне оештырырга була.

***Мәхәлләләрне финанслау***

XIX гасырда яшәгән татар имамыннан аермалы буларак, бүгенге көндә имамга мәчет өчен финанслар эзләүгә күп көч түгәргә туры килә. Элек мәчетләрне мәхәллә, милли буржуазия акча белән тәэмин итеп торган, мәчетләр төзегән, мәктәп һәм мәдрәсәләрне тоткан. Руханилар вәгазь һәм гыйльми эш белән мәшгуль булганнар. Бүген татарларга дини тәгълимат традициясен торгызу кирәклеге турында күп сөйлиләр. Монда барысы да бик гади: имамнарга ислам фәннәре белән шөгыльләнергә вакыт калсын өчен, аларны акча эзләүдән азат итәргә кирәк. Намаз, дәгъвәт кебек вазифаларын алар Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен болай да башкарачак, ләкин мәчет һәм гаиләләре өчен акча эзләүгә имамнарның бик күп вакытлары үтә.

Безнең эшмәкәрләрнең мәчетләрнең көндәлек тормышындагы проблемаларны чишүдә булышырга теләкләре уянмыйча, дини тәгълиматны торгызу турында уйларга бик кыен. Бу мәсьәләдә дәүләткә ышанып кына ятарга ярамый, үзебезнең тырышлыгыбыз да кирәк, мәчетләр, дини уку йортлары өчен җаваплылыкны мөселманнарга үз кулларына алырга кирәк.

Әлбәттә, имамның абруе зур булсын дисәк, ул мөселманнар өчен үрнәк булып торырга тиеш. Гомумән, имамнар өстендә булган иң зур бурыч – ислам dиненең киләчәге. Кызганыч, халык руханилар турында һәрвакыт яхшы уйламый, шуңа күрә дә, бүген имамнарга башкаларга караганда ике-өч тапкыр яхшырак булырга кирәк. Шул очракта гына кешеләр мәчеткә йөри башлаячак, һәм эшмәкәрләрдә мәчетләргә булышу теләге уяныргa мөмкин.

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезнең мәхәлләдә ни хәлләр бар? Кызыклы яңалыкларыгыз турында безгә язып, башка мөселман кардәшләребез белән дә бүлешсәгез иде. Безнең электрон адрес: naubahar67@list.ru**



# Мәүлидме бидгатьме?

**Ислам дөньясында билгеләп үтелә торган бәйрәмнәр һәм әһәмиятле вакыйгалар арасында Мәүлид үзенчәлекле бер урын алып тора. Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре яки Мигъраҗ, Бәраәт, Кадер кичәләре хакында мөселманнар бер фикердә булса, Мәүлидкә, ягъни Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көнен билгеләп үтүгә карата аларның фикерләре аерыла. Хәзер дә ислам динен тотучылар арасында Аллаһ Рәсүленең туган көнен билгеләп үтүчеләр байтак, әмма: "Мәүлид ул - бидгать, ягъни дингә кертелгән яңалык", - дип әйтүчеләр дә юк түгел. Шуңа да: "һәр бидгать ул адашу, ә һәр адашу - җәһәннәмгә илтә", - дигән хәдискә нигезләнгән хәлдә бүген без: "Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көнендә һәм дә рабигыль-әүвәл ае дәвамында аны искә алып салаватлар әйтү, аңа мәхәббәтебезне белдереп, ялкынлы вәгазьләр сөйләү җәһәннәмгә кереп китүебезгә сәбәп буламы?" - дигән катгый сорау бирергә мәҗбүрбез. Галимнәр бу хакта ни диләр? Шушы язма әлеге сорауга азмы-күпме ачыклык кертү максаты белән әзерләнде.**

Сәхабәләр вә табигыйннар гасырында Мәүлид үткәрү булмаган һәм моны без берсүзсез танырга тиешбез. Ләкин шунысын да билгеләп үтәргә кирәк - Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) исән чакта эшләнмәгән кайбер гамәлләр соңрак, нәкъ менә сәхабәләр вә табигыйннар тарафыннан гамәлгә кертелә. Әйтик, җомга намазында икенче азан әйтелә башлый, Гомәр (р.г.) халиф булган чорда зикер-тәсбихне мәчеттә җәмәгать белән башкару тәртибе кертелә, Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның соңгы Рәсүленнән махсус күрсәтмәләр булмаса да, фикыһ, гакыйдә, тәфсир кебек фәннәр барлыкка китерелә, шулай ук Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) тормышын, пәйгамбәрлек миссиясен яктырта торган Сира дигән фән дә формалаша һ.б. Әлбәттә, Коръән һәм сөннәттә искә алынмаган, әмма соңрак гамәлгә кертелгән шушы яңалыклар ислам дине үсешенә, мөселманнар өммәтенә шактый зур файда китерә.

Мәүлидкә килгәндә, Аллаһның ахыргы илчесен аның туган көнендә олылау, хөрмәтләү һәм искә алу турында шәригатьтә бернәрсә әйтелмәсә дә, гомуми мәгънәдә аңа ихтирам вә мәхәббәт белдерү - ислам диненең әһәмиятле асыл-нигезе булып санала. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә Үзе Мөхәммәд Пәйгамбәрне (с.г.в.) олылап искә алырга куша: ***"Дөрестән дә, Аллаһ та, Аның фәрештәләре дә Пәйгамбәргә салават әйтәләр. Әй иман китерүчеләр, сез дә Пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәләмнәрегез белән сәләмләгез!" ("Әл-Әхзаб" сүрәсе, 56 нчы аять).*** Мәүлид кебек чаралар исә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) салават әйтүнең, аңа мәхәббәт баглауның мөбарәк бер чагылышы булып тора.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең: "Мине үз мөлкәтеннән, гаиләсеннән һәм барлык кешеләрдән дә ныграк яратмыйча, беркем дә чын мөэмин булмас", - дигән хәдисе бар. Ә Пәйгамбәрне (с.г.в.) чын йөрәктән яраткан кеше аның туган көнәнә дә, һичшиксез, битараф кала алмыйдыр. Мөхәммәд галәйһиссәлам үзе дә һәр дүшәмбе көнне ураза тотуның сәбәбен, мин бу көнне туганмын, шуңа дүшәмбене ураза тотып билгеләп үтәм, дип аңлаткан. Шушы дәлил-аңлатмаларга нигезләнеп, шактый күп ислам галимнәре Мәүлид чараларын үткәрүне хуплаганнар. Алар арсында имам хафиз ибн Хаҗәр Әскаләни, имам Суюти, ә заманында Әл-Әзһар университетының Фәтвалар буенча комитет башлыгы булып торган шәйх Гатиййәһ Сакыр хәтта: "Бүген Мәүлидне билгеләп үтү аеруча кирәкле эш, чөнки башка - дөньяви вакыйгаларны бәйрәм итү белән мавыгып киткән яшьләр, мөселманнар өчен мөһим булган тарихи көннәрне оныта башладылар", - дип борчылып әйткән иде. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган көнен билгеләп үтү ул - аңа мәхәббәт белдерү һәм аның сөннәтенә ияргергә кирәк булуны искә төшерү максатыннан рөхсәт ителә, диде шәйх Сакыр.

"Әл-Әхзаб" сүрәсенең 21 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: ***"Тәхкыйк, Аллаһ Рәсүлендә сезгә ияргергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр",*** - дип әйтә. Шуның белән бергә аның мөхтәрәм сәхабәләре тормышыннан да үрнәк итеп сөйләрлек гыйбрәтле хәлләр шактый күп. Бик кыйммәтле булган шушы мәгълүматны мөселманнарга җиткерү өчен Мәүлид кебек чаралар бер дигән мөмкинлек булып тора.

Бу уңайдан фәтвалар буенча Европа шурасы рәисенең урынбасары Фәйсал Мәүләви болай ди: "Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) вафатыннан соң шактый күп вакыт узгач, аның холкы һәм тормыш рәвеше турында мәгълүмат саега, Аллаһ илчесенә хас булган гадилек, тыйнаклык, миһербанлык, кайгыртучанлык сыйфатлары хакында ишетмәү-белмәү сәбәпледер, яңа буын мөселманнарының калебләре рәхимсезләнә, катылана башлый. Мозаффар исемле хаким (ул ихласлы мөэмин була), шушы вәзгыятьне исәпкә алып, мөселман галимнәрен җыя һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) тормышын һәм күркәм сыйфатларын тасвирлауга багышланган китап төзүне таләп итә. Шул галимнәрдән ул Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең туган көнен билгеләп үтү мөмкинлеге хакында да фикер алышып, фәтва бируләрен сорый. Галимнәр бу тәкъдимне хуплыйлар, шуннан соң Мәүлидләр үткәрү күп җирлекләрдә гадәткә кертелә һәм күркәм традициягә әверелә. Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк, әлеге чара Аллаһы Тәгалә тәгаенләп раслап куйган бер гыйбадәт төре итеп түгел, ә мөселман галимнәре уздыра килешеп гамәлгә кертелгән бер күркәм гадәт булараk үткәрелә. Шәригать исә гамәлгә кертелгән гадәтне йә кире кагарга, йә рөхсәт итәргә тиеш. Бу очракта сүз Пәйгамбәр (с.г.в.) тормышын һәм сыйфатларын искә төшерү турында бара, шуңа күрә дә бу чараны оештыруда бик күп файда, ә катнашучылар өчен, иншә Аллаһ, әҗер-саваплар барлыгы да аңлашыладыр..."

Фәйсал Мәүләви фикерен тулыландырып, Мисыр мөфтие, шәйх Али Җуманың да Мәүлид хакында әйтелгән сүзләрен китерү урынлы булырдыр. Әлеге мәсьәлә буенча мөфти болай дип әйтә:

– Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) - кешеләрнең әфәндесе, барлык пәйгамбәрләрнең башлыгы, Рабыбызның сөеклесе, кешелеккә рәхмәт итеп җибәрелмеш Аллаһының Рәсүле һәм ул бу дөньяга килгән мөбарәк көн, һичшиксез, гадәти булмаган, иң яхшы көннәрнең берседер. "Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган көнен билгеләп үтәргә ярыймы?" - дигән сорауга каршы икенче бер сорау куярга мөмкин: "Мөселманнар аның туган көне уңаеннан сөенергә тиешме, әллә көенергәме? Әллә бернинди хис-тойгы белдермичә, битараф калыргамы?" Мөселман галимнәренең бөтенесе дә, ихласлы мөэминнәр бу көнгә шатланырга тиеш, дигән фикердә тора. Шулай да, һәр мәсьәлә буенча безгә Коръән белән сөннәттә чагылыш тапкан сылтамаларга нигезләнү зарур...

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, ул җирле яһүдиләрнең Муса галәйһиссәламнең Фиргавеннән котылу көнен бәйрәм итүләрен күрә һәм: "Без Муса пәйгамбәргә лаеклырактыр, ул - безнең өчен дә пәйгамбәр!" - дип әйтә. Соңыннан Мөхәммәд (с.г.в.) һәм аның сәхабәләре Муса галәйһиссәламнең котылу көнендә ураза тоталар, шушы тарихи көннең вакыйгаларын искә төшереп, аны билгеләп үтәләр. Бүген дә мөселманнар әлеге көнне Гашүрә көне буларак билгеләп үтәләр.

Белүебезчә, Коръән-Кәримдә төрле пәйгамбәрләр белән бәйле булган гыйбрәтле кыйссалар китерелгән. Моның максатхикмәтен аңлатып, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәламгә мондый аять индерә: ***"Рәсүлләрем турындагы хикәяләр белән Мин синең күңелеңне ныгытмак буламын. Аларда синең өчен хакыйкать һәм гыйбрәт бар, ә мөэминнәр өчен - зикер, вәгазь-нәсыйхәт" ("һуд" сүрәсе, 120 нче аять).*** Әгәр мөселманнар шушы аятькә бинаэн рәвештә Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) тормышыннан алынган гыйбрәтле кыйссаларны искә төшереп, бер-берсенең калебләрен ныгытсалар, моннан, иншә Аллаһ, файда күп булачак. Әлеге вәгазьләрнең Мөхәммәд (с.г.в.) туган айда - рабигыль-әүвәл дәвамында оештырылуыннан да, шәт иншә Аллаһ, зыян булмас.

Бүген Мәүлидне тәнкыйтьләүчеләр кайчандыр: "Асфальт та, теш щёткасы да, танк белән самолёт та бидгать!" - дип шушы һәм башка бик күп дөньяви әйберләрне хәрамга чыгардылар. Әмма акыллы кешеләр бу нәрсәләрнең цивилизация җимешләре, Аллаһ Рабыбызның бүләк-нигъмәтләре булуын аңлаткач кына, хаталарын аңлап, башка – гыйбадәткә якынрак булган нәрсәләргә дәгъва белдерә башладылар һәм ... микрофон аша азан әйтүне бидгать дип игълан иттеләр (янәсе, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) заманында азан микрофонга әйтелмәгән). Бүген Мәккә белән Мәдинәдә дә, башка мөселман илләрендә дә халыкны намазга микрофон аша чакыралар һәм моның реаль файдасын күргән "бидгать белән көрәшүчеләр" хәзер инде тындылар. Әмма нәрсәгә дә булса бәйләнәсе, кемне дә булса тәнкыйтьлисе килү теләге сүрелмәгән, күрәсең.

Дәгъва белдерергә яратучы "чиста ислам" тарафдарлары, гадәттә, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Безнең эшебезгә исламга кагылышы булмаган нәрсә кертелсә, ул кире кагылачак", - дигән сүзләрен төп аргумент итеп файдаланалар. Әмма бу хәдиснең асыл-нигезен тәшкил итүче гыйбарә - "исламга кагылышы булмаган" дигән сүзләр, ягъни гамәлгә кертелгән яңа нәрсә ислам дине тәгълиматына бөтенләй тәңгәл килми икән, бу нәрсә кабул ителми һәм кире кагыла, әгәр тәңгәл килә икән - бу яңа нәрсә "бидгахәсәнә", ягъни яхшы яңалык булып санала. Әйтик, шул ук микрофон ярдәмендә азан тавышы күпкә көчәйтелде, җәмәгать намазында да, имам микрофонга укыган очракта, күбрәк мөселманнар катнаша ала. Моңа бәйле рәвештә: "Мөселманнарның Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көнендә аны искә алып салаватлар әйтүе, бер-берсенә аның холкы, күркәм сыйфатлары, фидакарь эшчәнлеге турында сөйләве, шулай ук җыелып вәгазьләнү, Коръән уку һәм догалар кылу ислам дине асылына тәңгәл киләме?" - дигән сорауга ничек җавап бирергә соң? Азмы-күпме дини белеме булган акыллы кеше: "Һичшиксез, тәңгәл килә", - дип җавап бирәчәк.

Шулай итеп, Пәйгамбәребез (с.г.в.) туган көндә шатлык хисләре белдерү, вәгазь кичәләре, башка чаралар оештыру хакында махсус шәригать күрсәтмәләре булмаса да, Аллаһ Рәсүленә карата хөрмәт вә мәхәббәтебезне күрсәтү, бер-беребезгә, җәмәгатьчелеккә шушы олуг шәхеснең тормыш юлын аның туган көне уңаеннан искә төшереп, тагын бер кат хәтеребездә яңартып алу - динебезнең нигез-асылы булып саналган "пәйгамбәргә иман" дигән мөһим принципның чагылышы ул.

Бүген без Мөхәммәд саллаллаһү галәйһи вәссәламнең сөннәтен өйрәнүгә, аның үрнәгенә, аның нурына бик мохтаҗбыз. Мөбарәк рабигыль-әүвәл аенда бу дөньяга килгән олуг Пәйгамбәр (с.г.в.) һәммәбез өчен дә үрнәк булсын, ул туу белән дөнья вә галәмне яктырткан могҗизалы Нур исә тормыш юлыбызны һәм калебләребезне даими нурландырып торсын.

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**



*Кукмара мәдрәсәсе*

# "БЕЗГӘ БӘЙРӘМ, БЕЗГӘ ШАТЛЫК, БЕЗГӘ НУР КИЛДЕ БҮГЕН..."

**Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлам дөньяга килгән мөбарәк көн - быелгы Мәүлид бәйрәме уртак шатлык, бергәлеккә, татулыкка омтылу сөенече булып, мөселман кардәшләребез күңеленә кереп калыр, мөгаен. Гыйнварның гадәти булмаган кар-бурансыз, җилсез тын кичендә тарихи Болгар каласының Ак мәчете Мәүлид ән-Нәби бәйрәменә дәрәҗәле кунакларны җыйды. Татарстанның үзеннән һәм Россия төбәкләреннән килгән дин әһелләре янәшәсендә дәүләт җитәкчеләренең һәм татар зыялыларының да булуы аеруча күркәм күренеш иде.**



"Мәүлид" сүзе гарәпчәдән "туу" дигәнне аңлата. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) рабигыль-әүвәл аеның 11еннән 12-сенә каршы кичендә (быел милади буенча ул 12 нче гыйнвардан 13енә каршы кичкә туры килде) дөньяга килгән. Мәүлид бәйрәмен болай зурлап үткәрү Россия территориясендә бары тик Кавказда гына сакланып калган иде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте киләчәктә аны бөтен Россия күләмендә зурлап уздыруны традициягә кертергә ниятли. Быелгы бәйрәмгә дә зур хәстәрлек күрелгән. "Хузур" нәшрият йортында бәйрәмне уздыру тәртибе турында "Мәүлид китабы"н бастырып, кунакларга тараттылар. Ахшам намазыннан соң, бәйрәм чарасы Коръән сүрәләре уку белән башланып китте.



*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин*

> ***"Аллаһ рәхмәтләре арасында иң зурысы - Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәламнең дөньяга килүе...***

Аннары кунакларны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләде. "Аллаһ рәхмәтләре арасында иң зурысы - Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәламнең дөньяга килүе... Динебез бер, мәзһәбебез - бер, Китабыбыз - бер, телебез - бер, таркаулык өчен бер сәбәп тә юк. Бердәм булып, Болгар җиренә җыелдык. Киләчәктә дә шулай булачак. Ак мәчет мөселманнарның уртак фикергә килү урыны булып кабул ителәчәк", - диде ул.



*Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов*

> ***"Әгәр милләтебезне, динебезне сакламасак, безнең киләчәгебез юк...***

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та кунакларны Мәүлид бәйрәме белән котлады. "Республикада зур уңышларга ирешәбез, әмма бер икътисад белән генә булмый. Әгәр милләтебезне, динебезне сакламасак, безнең киләчәгебез юк", - диде Президент, Мәүлидкә килүчеләргә рәхмәт белдереп.

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев исә, тарихи һәм мәдәни мирасны торгызу буенча соңгы елларда Болгарда күп эш башкарылуын әйтеп үтте. "Бүген Ак мәчеттә Мәүлид бәйрәме уздырылу әнә шул зур эшчәнлекнең нәтиҗәсе", - диде ул.


Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе Шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин: "Мәүлидне инде 1425 ел дәвамында бәйрәм итәләр. Бездә бу көнне бәйрәм итикмеюкмы дигән сорау юк. Чөнки Аллаһ илчеләрендә гөнаһ юк. Шул үрнәк белән мөселманнар һидәяткә ирешкәннән бирле, без аны хөрмәтлибез", - диде һәм бабаларыбызның Аллаһ динен мөбарәк Болгар җирендә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сәхабәләреннән кабул итүен дә искәртеп үтте.

Мәүлид касыйдәсен көйләп, салаватлар әйтеп, дога кылганнан соң, бәйрәм мул сыйлы табын янында дәвам итте.



*Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев*


***"Ак мәчеттә Мәүлид бәйрәме уздырылу – тарихи һәм мәдәни мирасны торгызу буенча соңгы елларда башкарылган зур эшчәнлекнең нәтиҗәсе...***





*Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе Шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин*

***"Бездә бу көнне бәйрәм итикме-юкмы дигән сорау юк. Чөнки Аллаһ илчеләрендә гөнаһ юк...***






Хәнәфи мәзһәбе буенча мөселманнар Мәүлидне ай дәвамында бәйрәм итә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) турында, аның изге эшләре турында сөйлиләр, салаватлар әйтелә, бәйрәм табыннары әзерләнә. Бу бидгать гамәл түгел микән, дип күңелендә шик йөртүчеләргә: "Мәчетләргә килегез, Мәүлид бәрәмнәрендә катнашыгыз, аның динебезне куәтләүгә, милләтебезне берләштерүгә ярдәмен тоеп, үзегез дә сөенерсез", - диясе килә.

Мәүлид үткәрүнең дөреслегенә егерме бер дәлил китергән бөек ислам галиме Шәех Мөхәммәд ибне Галәви әл-Мәлики (1946-2004) үзенең мәшһүр хезмәтендә менә нәрсә ди: "Пәйгамбәрне (с.г.в.) олылауның шәригатьтә кануни нигезе бар. Ә затлы бу туган көн уңаеннан шатлык белдерү, сыйлар әзерләп, мәҗлесләр оештыру, Аллаһы Тәгаләне зикер итәр өчен кешеләрне җыю, ярлы һәм мохтаҗларга ихтирам һәм ярдәм күрсәтү - Пәйгамбәребез (с.г.в.) аша безне Үзенең чын туры диненә алып чыгуы, Мөхәммәд Пәйгамбәрне (с.г.в.) җибәреп, безгә зур рәхмәт күрсәткәне өчен Аллаһы Тәгаләгә олылавыбызны, шатлыгыбызны, рәхмәтебезне белдерү ул".

**Нәүбәһар КӘБИРОВА**

**"(Әй, Мөхәммәд) Без сине бары рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек".**

*("Әнбия (Пәйгамбәрләр)" сүрәсе, 107 нче аять).*

# ПӘЙГАМБӘР ТУДЫ

**Җир йөзенә ай калыккан, нур чәчелгән көн бүген,**
**Мәңге бәхет тәхетенә юллар ачылган көн бүген!**
**Дөньяда вәхшәт вә золмәтләр бетеп, хаклык килеп,**
**Барча батыл тетрәгән, потлар егылган көн бүген!**

**Җирләр, урманнар, болыннар гөр килә шатлык белән,**
**Сайрый кошлар, сандугачлар яудыра тәсбих бүген!**
**Якты кояш җир йөзенә сиптереп куйган нурын,**
**"Тугъды хаклык, килде шатлык"ны сөйли һәркем бүген!**

**Безгә бәйрәм, безгә шатлык, безгә нур килде бүген!**
**Безгә гыйлем, безгә хаклык, безгә нам тугъды бүген!**
**Яшәсен ул гали зат намы тәмам шәүкәт белән,**
**Яшәсен ислам, мөселманнар тәмам гыйззәт белән!**

***Зыя ЯРМӘКИ***



**Һәр айның икенче дүшәмбесе - Диния нәзарәтендә казыйлар җыела торган көн. Конференцияләр залындагы зур өстәл артына утырып, алар сәгатьләр буе берәр мәсьәләне уртага салып сөйләшәләр, киңәшләшәләр. Колак чите белән генә ишетеп калдым, бу юлы казыйлар мине күптән кызыксындыра торган талак мәсьәләсен күтәрделәр. Татарстанның баш казые, үрнәк мөселман гаиләсе башлыгы Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ белән әңгәмә кору өчен моннан да кулайрак тема булмас дип, аның янына юл тоттым.**



# Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ:

# «ЯХШЫГА ЯХШЫНЫ КУШКАЧ КЫНА ЯХШЫ БУЛА»

- Сезне генә түгел, бүгенге көндә безне - казыйларны да иң борчыган мәсьәлә инде бу, чөнки халыкта, аеруча хатын-кызларда, талакка кагылышлы сораулар бик күп. Ир кеше бит ул аерылырга теләсә, хатынын аера да җибәрә. Хатын-кыз аерылырга теләсә, казыйга мөрәҗәгать итәргә тиеш. Ә кайсы очракларда хатын-кыз талак сорый ала, казый аңа рөхсәт итә ала (тормышта бит төрле хәлләр була: кемдер хатынын ташлап китә, гаиләсен матди яктан тәэмин итми, кайсын төрмәгә утырталар)? Казыйларга эшләргә җиңел булсын дип без шуның бер положениесен әзерләргә дигән фикергә килдек.

**- Казыят бу мәсьәләдә мөселманнарга-мөслимәләргә генә ярдәм күрсәтәме?**

- Юк, без дөньяви кешеләрнең дә мөрәҗәгатьләрен карыйбыз. ЗАГСта аерылышалар икән, аны да бер талакка санарга дигән нәрсәне положениегә керттек. Хәзер икенче, өченче хатын белән никахланып торучылар бар. Без дөньяви илдә яшәсәк тә, хакыйкатьтә икенче, өченче хатын алу җинаять саналмый, рөхсәт ителә, әмма алар ЗАГСта теркәлмиләр бит инде. Аерылган чакта ул хатыннарга мөлкәт тими, закон буенча бернәрсәгә дә хокуклары юк. Шуңа күрә әлеге положение буенча икенче-өченче хатын булып никахланучыларга никах килешүе төзергә тәкъдим итәбез. Аерылган очракта шул никах килешүе карала.

**- Хәзрәт, аерылышулар саны буенча хәзер мөселманнар дөньяви парлардан һич кенә дә калышмый икән...**

- Элек бит яшьләр әти-әни киңәше белән өйләнешкәннәр. Өлкәннәр булачак килен-кияүнең нәсел-нәсәбен тикшергән. Җәмгыять үзен саклар өчен нәселне сакларга тиеш. Без бит үзебездән соң яхшы балалар калдырырга бурычлы. Яхшыга яхшыны кушкач кына яхшы була. Ә бүген бер намаз укучы икенче намаз укучыны күрә дә, булды, намаз укый, алам, ди. Нәселен дә, холкын, гадәтен дә белми ул аның. Югыйсә бит инде сыер алганда да нәселе нинди икән дип кызыксынабыз. Гомәр (р.г.) бер кешедән, син аны яхшы беләсеңме, дигәч, тегесе, яхшы беләм, мин аның белән бер мәчеткә йөрим, ди икән. Шуннан Гомәр (р.г.) болай дигән: "Юк, син аны яхшы белмисең, яхшы белер өчен күрше булып яшә, юлга чыгып кара яки акча биреп тор". Намаз уку белән генә эш бетми бит әле. Бу намаз укымасыннар дигән сүз түгел.

Никах бит ул ирләрнең телен, хатын-кызның аягын бәйли. Хатын-кыз иренең рөхсәтеннән башка өеннән чыгарга тиеш түгел, ир кеше ашыгып, хатынга талак әйтергә тиеш түгел. Ә хәзерге дини яшьләребез өйләнешәләр дә, кечкенә генә бер авырлык килеп чыгуга, талак кычкыралар. Шаккатам мин моңа! Берне генә түгел, өчне әйтәләр бит әле. Аерылышу өчен берсе дә җитә югыйсә. Ир бер талак әйтеп, өч ай хатыны белән якынлык кылмаса - хатын ирекле. Теләсә үз иренә, теләсә икенче иргә чыга ала. Ә өч талак әйткәч, башка иргә чыгып аерылмыйча, ул бу иренә кайта алмый. Үзебез иман, сабырлык дибез, ә шундый җаваплы эштә сабырсызлык күрсәтәбез.

**- Сабырлык дигәннән, хәзрәт, менә сез үрнәк гаилә булып, хатыныгыз белән ничә ел матур гына яшәп ятасыз. Гаиләне саклауның сере нәрсәдә - сабырлыкта гынамы?**

- Әлеге дә баягы шул сабырлыкка кайтып кала инде ул. Ике якка да сабыр булырга кирәк. Бер төркем ирләр хатыннарыннан зарланып утыралар икән, берсе зарланмый ди. Син ник зарланмыйсың, хатының шулай бик әйбәтмени, дигәч, тегене кеше: "Без өйләнешкәндә беребез тилергәндә икенчебез акыллы булып калырга сүз куештык", - дигән ди. Ачу - шайтаннан. Кемнең ачуы чыкса да, ул тиле кеше хөкемендә була. Тиле кеше белән вакланмыйбыз, аңа нәрсәдер исбатларга да тырышмыйбыз бит инде. Гаиләдә тавыш чыгып, хатын кычкыра башласа, шул чакта ир хатынга әнисенең кем икәнен әйтеп куйса, хатын секундның йөздән бер өлешендә аның бабасының анасы кем икәнлеген әйтеп бирәчәк. Берең тилергәндә икенчең акыллы булып калу ул икенчеңә сабыр итеп калырга кирәк дигән сүз. Өйләнешкәндә андый гыйлемнәребез юк иде үзе, шулай да Гөлфания белән без ачуланышабыз, үпкәләшәбез икән, икенче көнгә калдырмаска дип килештек.

**- Ә ачуланышканда кайсыгыз башлап эндәшә?**

- Кайсыбызның җай килә торгандыр инде, карчык дипломатрак түгел микән, дим. Үзе сөйләгән иде: "Бервакыт, менә мин сөйләшмәсәм син ничә көн сөйләшми тора аласың, дип сорадым, - ди. - Син, и-и, нәрсәсе бар аның! Мин гел кеше арасында, болай да сөйләшеп арып бетәм, бер ай сөйләшми дә тора алам, дип әйткәч, эш яман икән, ничек булса да сөйләшергә кирәк икән, дигән нәтиҗә ясадым". Уен-көлке белән әйткәнмендер инде мин аны... Безнең бергә тора башлавыбызга әле күп түгел, 32 ел гына, Аллага шөкер... Тормышның авыр вакытлары да, житмәүчелек тә була, менә шул вакытта хатын-кыз акыллы булып, сабыр итсә әйбәт инде. Бервакыт хатынның бер кофтага күзе төшкән, алтмыш сум гына инде үзе, алып биреп булмады. Бик кызыкканын да беләм, акча юк! Ул бит, менә шуны да ала алмыйсың, дип тә әйтә алган булыр иде. Алай димәде, сабыр итте. Без әти-әни белән бергә тордык. Аллага шөкер, хәзер дә бер түбә астында дүрт буын яшибез. Әни исәнсау, инде үзебез килен төшердек. Киленебезнең бусы да бик акыллы, ул ике кайнана өстенә килде. Хатын-кызлар сабыр булмаса булмый ул.

**- Киленнәрнең нәселнәсәбен карап алгансыздыр инде...**

- Әйе, киленнәребез яхшы танышларыбызның кызлары. Олысы дин гыйлемен миннән алган иде. Ихтималлык теориясе буенча һәр очраклы ике эшнең берсе генә уңышлы була. Бүген бит гаилә кору очраклылыкка куелган, шуңа күрә гаиләләр таркала да. Әти-әнинең бала алдында биш бурычы бар: матур исем кушу; хәләл ризык белән тукландыру; дөньяви, дини гыйлем бирү; бала алдында бер-береңне кимсетмәү; никахка булышу. Бүген никахка булышу дигәнне күп кеше зур табын әзерләү дип күз алдына китерә. Бу алай түгел. Һәркемнең аралашкан танышлары, танышларының танышлары була. Берсендә кыз, икенчесендә егет бар, дигәндәй... Өлкәннәр аларны бер-берсенә күрсәтеп, нәселе турында аңлатып, әхлакый яктан ничек яшәүләрен сорашырга-белешергә тиеш.

**- Узган ел Башкортстанда булып кайткан журналистлар аша кодагызның: "Киленебез шундый тәрбияле, шулай булмыйча Җәлил Фазлыев тәрбиясен алган бала бит ул", - дигән сүзләре килеп иреште. Сез балаларыгызны ничек тәрбияләдегез, хәзрәт?**

- Безнең үзебезне әби-бабай дини итеп тәрбияләде. Ә мин үз балаларымны алай тәрбияләргә кирәк түгелдер дип уйлаган идем башта. Чөнки армиядә хезмәт иткәндә, институтта укыганда башкаларның теләсә нәрсә ашаганын, теләсә ничек яшәгәнен күргәч, без үзебезне чиклибез шикелле тоелган иде. Мин үз гомеремдә аракы эчмәдем, тәмәке тартмадым, дуңгыз ите ашамадым, сүгенмәдем. Балалар бераз үсә башлагач карыйм - хайван да хайван, болар да хайван... Болай итеп булмый бит инде, минәйтәм. Әби-бабай шикелле ашарга утырганда "бисмилла" әйтергә, ашагач, азанны ишеткәч дога кылырга, аннары намаз догаларын өйрәтә башладым. Тугыз яшь тулганда, туган көнегезгә бер намаз бүләк итәм, ун яшегезгә тагын берне, дип намазга бастырдым. Аллага шөкер, унбер яшьтән алар биш вакыт намазда.

**- Иптәшләре арасында кыенсынмадылармы соң?**

- Аларга иптәшләре дә иярде, чөнки чоры шундый иде бит. 1992 нче елны мәчеттә 120 бала укыттым, 1993 тә балалар саны 140 ка җитте. Шуларның 120 се намаздан имтихан бирде. Уйлап карагыз әле, бер авылдан бит ул! Үзебезнең ике улыбыз Булат белән Алмаз да, киленнәребез, кызыбыз Айсылу белән киявебез - һәммәсе дә намазлы. Ислам кануннары белән яшиләр, Аллага шөкер. Инде менә дүрт оныгыбыз үсеп килә. Быелгы хаҗ чыгымнарыбызның яртысын олы улыбыз (алар башка чыгып торалар) үз өстенә алды, бу да бик зур сөенеч бит инде. Минем хаҗга дүртенче тапкыр баруым, бу юлгысы бигрәк тә ошады. Болай итеп тә хаҗ кылып була икән, дип кайттык. Шулхәтле тырышып оештырганнар. Хатын белән дә сөйләштек әле, моннан да матур хаҗ булмас, бүтән бармаскадыр инде, истәлек булып калсын, дидек.

Инде хаҗ турында сүз чыккан икән, әйтми кала алмыйм. Халык арасында кайвакыт, клиент һәрвакыт хаклы, дип арттырып җибәрүчеләр дә булгалый. Без бит анда клиент та, турист та түгел, җәмәгать, ә гыйбадәт кылырга барабыз. Гарәфә тавы итәгенә басып, күзләребездән яшь агыза-агыза: " И Раббым, без Синең каршыңда, нишләтсәң дә риза",- дигән сүзләр белән Аллаһы Тәгаләгә ялварабыз. Ә үзебез кечкенә генә авырлык килеп чыкты исә шундук ризасызлык белдерә башлыйбыз. Берәү дә хаҗда икенче кешегә караганда артыграк гамәл кылмый. Булган авырлыкка сабыр итүгә һәм янәшәңдәге кешегә күркәм мөгамәлә кылуга савап языла. Менә шуны күп кеше аңлап бетерми. Моны хаҗилар белән эшләп җиткермәү дип саныйм мин. Безнең төркемдә - Кукмара, Балтач хаҗилары арасында, Аллага шөкер, алай көйсезләнеп йөрүче кеше булмады. Җитәкчебез Илшат хәзрәт Сафин үзе дә Балтачта дәресләр алып барган иде, алар хаҗиларны югары дәрәҗәдә әзерләгәннәр. Нияте булган һәркемгә хаҗ гыйбадәте кылу насыйп булса иде. Ә менә кайткач, хаҗи исеменә лаек булып яшәү - безнең өстәге бик зур бурыч.

**Нәүбәһар КӘБИРОВА**

**Хөрмәтле укучыларыбыз. Әгәр дә ислам динен күптән түгел генә кабул итеп, гыйбадәтләрне яңа гына үти башлагансыз икән, бу сәхифәбез сезгә бик зур ярдәмче булыр дип уйлыйбыз. Исламны ничек кабул итәргә? Ислам дине башка диннәрдән нәрсә белән аерыла? Нәрсә ул мәзһәб? Исламда хатын-кызга мөнәсәбәт нинди? Ризыкны ничек сайларга? Шушы һәм башка бик күп сорауларга җавапларны без Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхәррирлегендә басылып чыккан "Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясе ярдәмендә бергәләп эзләрбез.**



# Дөньяның асыл тарихы

Иң башта без яшәгән дөнья булмаган. Ләкин иң Бөек, Камил һәм иң Кодрәтле зат - Аллаһы Тәгалә һәрвакытта да булган. Ул үзенең көч-кодрәте белән җиһаныбызны һәм анда булган бар нәрсәне барлыкка китергән. Кеше дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылган. Адәм галәйһиссәлам дөньяда беренче кеше һәм беренче ислам дине пәйгамбәре булган.

Вакытлар узган, буыннар алмашынган. Тора-бара Адәм галәйһиссәламнең нәселе камил иманнарын югалтып, табигать, әйбер һәм кешеләрне иләһиләштерә, динне үзләренең теләкләренә яраклаштыра башлаганнар. Шуннан Аллаһы Тәгалә ислам юлына күндерү максатыннан, халыкка яңа пәйгамбәрләр һәм илчеләр җибәргән. Алар кешеләргә Аллаһының Берлеген аңлаткан. Ә инде күпаллалыктан ваз кичмәгән гөнаһлы затларны Аллаһы Тәгалә җәзалаган.

Кешеләр ялгышларга һәм күпаллалыкка чумган саен, Аллаһы Тәгалә аларга исламның туры юлына өндәүче пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр җибәрә торган. Тугры юлга басу мөмкинлеге барлык кабиләләргә һәм халыкларга да бирелгән, ләкин барысы да бу форсаттан файдаланырга теләмәгән.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам - кешеләргә җибәрелгән соңгы Пәйгамбәр. Аннан соң башка пәйгамбәрләр булмаячак. Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең кабиләсенә генә түгел, бөтен кешелек дөньясына ислам динен тарату өчен җибәрелә. Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдкә (с.г.в.) егерме өч ел дәвамында аз-азлап Илаһи китап - Коръәни Кәримне индерә. Әлеге китапта кешеләргә ахирәт көненә кадәр яшәрлек кулланма бирелгән. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) яшәү рәвешен Раббыбыз барлык кешелек өчен дә үрнәк булырлык иткән. Мөселманнар Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сөйләгәннәре һәм эш-гамәлләре безгә хәдисләр - аның васыятьләре, эшләнгән эшләре һәм сыйфатлары рәвешендә килеп ирешә.

Аллаһы Тәгалә кешелеккә тормышын тәртипкә салучы, яшәешнең мәгънәсе турында белемнәр бирүче, дөньялыкта һәм ахирәттә бәхеткә ирешергә ярдәм итүче дин биргән. Диннең нигезе иман, ислам һәм ихсаннан гыйбарәт.

Гомәр (р.г.) әйткән: "Бервакыт, без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам янында булганда, безнең янга ап-ак киемнәр кигән, чем-кара чәчле таныш булмаган бер кеше килеп басты. Кыяфәтенә караганда, ул юлчыга охшамаган иде. Бу кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламгә тез башлары орынып торырлык якынлыкта килеп утырды да: "Әй, Мөхәммәд, миңа ислам турында сөйлә әле", - диде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам: "Исламның мәгънәсе Аллаһы Тәгаләнең Барлыгына һәм Берлегенә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Аллаһы илчесе булуына иман китерү, намаз уку, зәкят бирү, рамазан аенда ураза тоту һәм, мөмкинлегең булса, хаҗ кылудан гыйбарәт", - диде. Әлеге кеше: "Син дөресен сөйлисең", - диде. Ә без аның сорау бирүенә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең сүзләрен раславына гаҗәпләндек. Аннан соң ул: "Ә хәзер миңа иман турында сөйлә инде", - диде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам: "Иманның асылы кешенең Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, илчеләренә һәм ахирәт көненә, яхшының да, яманның да тәкъдирдә билгеләнүенә ышанудан тора", - диде. Бу кеше: "Син дөресен әйттең",- диде. Бераздан ул: "Ихсан турында да сөйлә инде", - диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам болай диде: "Ихсанның асылы: Аллаһы Тәгаләгә табынуың Аны күргәндәгедәй булсын, ә инде Аны күрмисең икән, дөреслектә Раббыбызның сине һәрвакытта күрүен истә тотарга кирәк". Шуннан бу кеше: "Ахирәт көне турында да аңлат инде", - дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам болай диде: "Бу хакта соралучы сораучыдан артык белми". "Алайса миңа аның галәмәтләре турында сөйлә",- диде ул. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам аңа: "Кол хатын үзенең хуҗабикәсен тудырыр, яланаяклы ач-ялангач көтүчеләр бер-берсе белән өйләренең биеклеге өчен узышыр", - дип җавап бирде.

Әлеге кеше китеп барды. Аллаһы илчесе салләллаһу галәйһи вәссәлам бераздан: "Әй, Гомәр, бу сорауларны биргән затның кем икәнен беләсеңме?" - дип сорады. "Раббыбыз һәм Аның илчесе бу хакта бездән яхшырак беләләр", - дидем мин. Шунда ул: "Чынбарлыкта сезгә динегезне өйрәтү өчен яныгызга килгән Җәбраил иде бу", - диде.

Динебезнең шушы өч төп юнәлешен исламның аерым фәннәре өйрәнә. Иманны - гакыйдә (дин белеме) фәне, исламны - фикъһ (ислам хокукы) фәне, ихсанны тәсәүүф (калебләрне пакьләү) фәне өйрәнә.



# Исламны ничек кабул итәргә?

Исламны кабул итүе бик гади. Иман китерү өчен "Әшһәду әл-ләә иләәһә иллал-лааһү үә әшһәду әннә Мөхәммәдән габдүһү үә рәсүлүһ" дип шәһадәт сүзләрен әйтергә кирәк. Мәгънәсе: "Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юклыгына, Мөхәммәднең Аллаһының колы һәм илчесе булуына шаһитлык кылам".

Исламны кабул итүче кеше түбәндә китерелгән дин тәгълиматларын таныйрга тиеш:

1. Аллаһы Тәгалә бердәнбер. Аның иптәше дә, углы яки кызы да юк.
2. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам Аллаһының соңгы Илчесе һәм аннан соң бүтән пәйгамбәрләр дә, илчеләр дә булмаячак.
3. Коръән - Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә индерелгән соңгы Илаһи китап һәм анда язылганнар чын хакыйкать.
4. Үлемнән соң яшәү - ул һәр кеше үлгәннән соң яши торган мәңгелек гомер. Бакый дөньяда һәр кеше үзенең изге гамәлләре һәм гөнаһлары өчен җавап тотачак.
5. Коръәни-Кәримдә язылганнар һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам хәдисләре тулы һәм ачык итеп бирелгән чын дөреслек һәм хакыйкать булып тора.

Әлеге төп дини тәгълиматларны кеше акылы һәм калебе белән чын, хак дип кабул итсә, мөселман була.

Диннең асылы түбәндәге сүзләргә нигезләнә:

"Мин Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына (пәйгамбәрләргә индерелгән беренчел рәвешләрендә), Аның илчеләренә, Кыямәт көненә, яхшының да, яманның да Бөек Аллаһы тарафыннан бирелүенә, үлгәннән соң тереләчәгебезгә ышанам".

Шәһадәт китерүне, гадәттә, ике шаһит янында мәчеттә башкаралар. Ләкин бу мәҗбүри түгел. Исламны япа-ялгыз булганда да кабул итәргә мөмкин. Гади генә әйткәндә, Аллаһының барлыгына һәм берлегенә, ә Мөхәммәднең Аның илчесе булуына ышанасыз икән, сез үзегезне мөселман санап, шәһадәт китерә аласыз.

Әгәр исламга башка диннән киләсез икән, сезгә башта элеккеге динегездәге карашлардан арынырга, исламга туры килмәгән фикерләрдән чистарынырга кирәк.

Диннең барлык гамәли күрсәтмәләрен дә үтәргә әзер булмасагыз да, исламны кабул итәргә мөмкин. Иң мөһиме - исламның барлык тәгълиматларын хакыйкать итеп кабул итәргә кирәк. Баштан ук барлык күрсәтмәләрне дә үти алмасыгызны белсәгез дә, бу ислам динен кабул итүне кичектерергә сәбәп була алмый. Гөнаһлы мөселман булуга караганда, бөтенләй мөселман булмау күпкә яманрак.

***(Газетабызның алдагы санында без иман һәм иманның алты баганасы белән танышырбыз, "Нәрсә ул тәүхид?" дигән сорауга җавап эзләрбез).***

# ВАЗЫЙФАБЫЗ БИК ТӘ ҖАВАПЛЫ

**Безнең Ак мәчет каршында 60 төркем оешып, аларда меңгә якын кеше башлангыч дини белем ала. "Якшәмбе мәктәпләре" дип аталсалар да, чынлыкта, алар атна дәвамында эшли. Ир балалар һәм кыз балалар төркемнәре бар. Татар телен белмәүчеләр өчен урыс телле төркемнәр оештырылган. Мәчеткә кемдер Коръән укырга, кемдер исә намаз хөкемнәрен өйрәнер өчен килә. Минемчә, без аларның барысының да ихтыяҗын канәгатьләндерергә тиеш.**

Бүгенге көндә "Якшәмбе мәктәпләре" өчен 1, 2, 3 еллык программалар тәкъдим ителде. Бу бик яхшы, димәк, укыту системасында бер эзлеклелек, тәртип барлыкка киләчәк. Әмма уку срогын ике - өч ел белән генә чикләргә кирәкми, чөнки бу дәвердә укучы башлангыч белемгә ия булып, дин белән танышырга гына өлгерә. Динне тагын да тирәнрәк аңлау өчен укуны дәвам итәргә кирәк. Бездә, мәсәлән, 17 ел мәчеткә укырга йөрүче әбиләр төркеме дә бар. Алар җыелышып Коръән укыйлар, хәзрәтләребезнең вәгазьләрен тыңлыйлар. Гомумән, бездә бер дәрес тә хәзрәтмөгаллимнәребез нәсыйхәтеннән башка үтми.

Хөрмәтле мөгаллимнәр! Аллаһы Тәгалә безгә зур вазыйфа - динсезлек афәтенә тарыган халыкка дини белем бирү вазыйфасын йөкли. Әлеге вазыйфаны тиешле дәрәҗәдә үтәгәндә генә без, иншә Аллаһ, ике дөнья бәхетенә ирешәчәкбез.

Журналист әфәнделәр, туташлар колагына да җиткерер сүзем бар. Бүген радиотелевидение, газета-журналлар аша динне пычрату бара. Шул сәбәпле халык мәчеткә балаларын китерми башларга да мөмкин. Ислам диненең асылын аңламыйча, дин турында мәкалә язмасагыз, очраклы кешеләрдән интервью алмасагыз иде сез.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да файдалы гыйлемнәр, сәламәтлек, иман байлыгы насыйп итсен.

**Әсфия БЕЛЯЕВА,**
**Чаллы шәһәренең "Ак мәчет" мәдрәсәсе мөгаллимәсе**

# НИЯТ

**Эш бүлмәбезгә бер-ике йотым су сорап килеп кергән бу мөлаем ханым турында башта ни уйларга да белмәдем. Бергәләп намазлар укып, чәйләр эчеп, нинди ният белән йөрүен белгәч, гаҗәпләнүемнең чиге булмады. Хәлимә апа Насыйбуллина бер бистәдә мәдрәсә ачу уе белән йөри икән, мөфти хәзрәт янына киңәшләшергә килгән. "Сез эшкуар да, берәр байның хатыны да түгел, ничек тәвәккәлләдегез?"- дип кызыксынуыма җавап итеп: "Аллаһ безне бу җиргә шуның өчен яралткан",- диде ул. Башта артык купшы сүзләр тоелса да, тормышы белән танышкач, моның шулай икәнлегенә тамчы да шигем калмады. "Дин юлында ихлас күңелдән йөрүчеләр юк ул хәзер", - дип фикер йөртүчеләргә җавап итеп, Хәлимә апа сөйләгәннәрне ничек бар шулай язарга булдым.**

"Бу ниятебез барып чыгар микән дип әй борчылдык инде. Игезәк сыңарым Әминә белән нәфел уразасы тота башладык, менә Аллаһының рәхмәте булсын үзеңә, син биргән су белән авыз ачтым. Уразаның җиденче көнендә Әминә төш күрде: без мәдрәсә өчен алган җирдә ямь-яшел чирәм үскән, имеш. Ниятебез тормышка ашар, иншә Алла.

Дингә килү өчен Аллаһ һәркемгә мөмкинлек бирә ул. Безне менә тормыш юлыбызда гаҗәеп чибәр, озын сары чәчле Фәридә исемле кыз белән очраштырды. Казанның элеккеге мэры Камил Исхаковның туганының кызы ул. Безгә кунакка килгәч, Фәридә, кызлар, сезнең комганыгыз бармы, миңа тәһарәт алырга кирәк, намаз вакыты керде, диде. Шаккаттык моңа. Минем үземдә дингә омтылыш яшь чагымда да булгалаган иде. Шулай бервакытны күрше әбидән сорыйм: "Сара апа, син менә ураза тотасың, ә без ник тотмыйбыз соң?"- дим. Шунда ул: "Сезгә дә кирәк тә бит, тотмыйсыз шул менә", - дип куйды. Аннан өйрәнеп, бер көн ураза тотканым исемдә. Әнигә элэкмәдә инде дин тотулар. Раскулачивать иткәннән соң бер җирдән икенче җиргә күчеп йөргәннәр. Аннары тагын бер талпыныш булды әле: Мәрҗани мәчетенә килдем дә, минем гарәпчә өйрәнәсем килә, дидем. Бер ир кеше, хатын-кызны хатын-кыз өйрәтергә тиеш, ә бездә абыстайлар юк, дигәч, нәүмизләнеп кайтып киттем инде. Тагын ун елдан без Фәридәне очраттык. Шуннан соң да бөтен намазларны укып, бирелеп дингә кереп китмәдек әле. Аллаһы Тәгалә Үзе сәбәбен тапты... Әминә туганым белән Салмычида җир алган идек. Бәхәсле җир булган икән, без аны-моны белмәдек. Бер кишәрлек җирне бишәр кешегә сатканнар, берәү хәтта асылынып та үлде ул чакта. Йөреп-йөреп тә очына чыга алмагач, аңладык без эшнең нидә икәнен - Аллаһы Тәгалә безне сыный. Әлхәмдүлилләһи, шул хәлдән соң дингә ныклабрак ябыштык.

> **«Уразаның җиденче көнендә Әминә төш күрде: без мәдрәсә өчен алган җирдә ямь-яшел чирәм үскән, имеш. Ниятебез тормышка ашар, иншә Алла».**

Әниебез авырып киткәч, аның янына Шәлегә күчеп яши башлаган вакыт. Беркөнне Борисково мәчетеннән дингә ихлас бирелгән Әминә абыстай, кызлар, әйдәгез, хаҗга барабыз, дип шалтырата. 72 нче елдан бирле правам бар, Казан белән Шәле арасында йөрергә машина алырмын дигән идем. Уйладым-уйладым да, юк, минәйтәм, тәҗрибәсез килеш юлда бер-бер хәл килеп чыкса, машинаң да булмас, үзең дә, хаҗың да. Шулай итеп хаҗны сайладым. Әминәбез 27 ел буе логопед булып эшләде. Балалар хакы кермәсен дип алар белән бер казаннан ашамады, менә шундый чиста күңелле кеше инде ул. Аның да пенсиясе җыелып барган иде, шулай итеп, Аллаһ безгә хаҗ сәфәре насыйп итте. Беркөнне Әл-Хәрәм мәчете юлындагы аптека яныннан узып барганда инвалид коляскасы күрдем, бәясе шундый арзан. Ул вакытта бездә андый коляскалар бик дефицит, өстәвенә кыйммәт иде. Кайтып, сөйләгәч, Әминә, ничекләр алып кайтырбыз икән аны, дип уйга калды. Ниятебез булганда, Аллаһы Тәгалә ярдәм итми калмас, дим. Чыннан да, колясканы китереп үк бирделәр, автобуска да бик җайлы гына кереп урнашты, самолетта, поездда да түзә алмаслык мәшәкате булмады. Инде алып кайтуын кайттык, бирергә кеше таба гына алмыйбыз бит. Ул вакытта социаль яклау министры булып Гүзәл Миңкина эшли иде. Теләгебезне җиткергәч, башта ышанмыйчарак торды: "Согуд Гарәбстаныннан алып кайттыгызмы? Булмас", - ди. Чиратта торучылар исемлеген барлагач, болар безгә бер кешене тәкъдим иттеләр. Менә гаҗәп: ул да безнең кебек игезәк сыңары булып чыкты.

Кәгъбәтулладан чыкканда елый-елый: "Әй, Раббым! Безне тагын монда чакырсаң иде", - дип сораган идем, Ул мине ишетте. Икенче елны пенсиямне алганда саклык кенәгәмә күп итеп акча күчергәннәр. Ялгышлыктыр, дип тикшертергә бардым. Бернинди ялгышлык та юк, Хәлимә Нәбиулловна, пенсиягә яңа гына чыгучыларга 14 нче хезмәт хакы күчергәннәр, диләр. Ул акчаны кулга алганда уема машина алу дигән нәрсә килеп карамады. Минем алда Киров урамыннан Лобачевский урамындагы мөфтият бинасына алып баручы 15 минутлык туры юл гына бар иде. Әни инфаркттан соң, башта аңа әйтергә курыктык, карап торырга кеше таба алмыйбыз гына бит. Эндәшмәгән бер кешебез калган икән. Равил хәзрәт Гайнетдиннең әнисе Миңниса апа, төнлә кирәкме, көндез кирәкме, тәүлек буе кирәкме - ничек тели шулай карыйм, дигән хәбәрен ирештерде. Әни әйтә, тәрәзәдән карыйм да, Миңниса апагызның



карга бата-бата безгә килүен күреп, күзләремә яшь тула иде, ди... Әминә белән без ул елны әти белән әни өчен хаҗ кылдык. Гарәфә тавында торганда, әниебезне дә намазга бастырсаң иде, дип сорадык, әлхәмдүлилләһи, намазга басып, бер ел намаз укып, бу дөньядан хаҗия булып китте.

Икенче хаҗдан кайтуыбызга кече сеңелем белән киявебез машиналарын яңартканнар икән, элеккесен сатарга булганнар. Әни, өр-яңа машина, арзанга гына саталар, әйдә, үзебезгә генә алыйк, дип бик кыстагач, машиналы да булып куйдык. Шулай итеп, мин 56 яшемдә рульгә утырдым. Хәзер хуҗалыкка кирәк-яракны Казаннан үзем алып кайтам.

Ә мәдрәсә ачу уе кече сеңелебезнең уллары белән сөйләшеп утырганда туды. Ниятең изге булса, Аллаһы Тәгалә ярдәм итү җаен барыбер таба ул. Энекәшләрне дингә китерү дә шулай булды бит. Бервакытны ниндидер бәйрәмнән соң Казандагы фатирыбызда балалар белән мәш килеп ятабыз. Артымнан тагылып диярлек йөргән алты яшьлек Булатыбыздан: "Ә синең тагын бер бүләк ала-сың киләме?" - дип сорап куйдым. Әти-әнием рөхсәт ит-мәсләр, ди бу. Юк, минәйтәм, алар ачуланмаслар, әмма бер шартны үтәргә кирәк булачак. Менә "Әлхәм" дигән дога бар, син аны бер кичтә өйрәнә алырсың микән, дим. Ярты сәгатьтә өйрәнде бу моны. Аннары "Ихлас", "Аятел Көрси"гә керешә. Матди яктан авыррак еллар иде ул. Шулай беркөнне кибеттә ап-ак уенчык машинкалар күрде болар. Апа, аның барлык ишекләре дә ачыла, диләр, күзләре ут яна инде. Кайттым да каян 300 сум акча алырга дип уйлыйм. Бөтен кышкы киемнәрнең кесәләрен актара торгач, җыйдым бит 300 сумны. Бу Аллаһының рәх-мәте бит инде. Йөгереп барып, шул машинкаларны алып кайтып, "Аятел Көрси"не өйрәнеп бетергәнгә Булатның кулына тоттырдым. Менә, минәйтәм, Аллаһ бөтенесен күреп тора, синең тырышлы-гыңны да күргән, дим. Муратына күрсәткәч, бик гаҗәпләнгән инде, әкренләп ул да теге догаларны өйрәнеп, "машиналы" булды. Инде бераздан әтиләренә, малайларны ислам институтындагы якшәмбе мәктәпләренә бирсәгез, ничегрәк булыр икән, дип сүз каттым. Атна саен йөрттеләр. Хәзер, әлхәмдүлилләһи, атнакич мәетләргә укыйлар. Муратыбыз биш вакыт намазлы, уразасын да тотты.

Шул энекәшләрем белән сөйләшкәндә, акчам булса мәчет йә мәдрәсә төзер идем, дип әйтеп куйган идем. Бу уй безгә тынгылык бирми башлады. Казаннан ераграк бер бистәдә ун сутый җир сатып алдык. Анда татарлар бик күп, ниятләре дә бар, гыйлемнәре юк. Аллаһы Тәгалә Үзе безгә шунда барып, динне куәтләргә куша кебек... Әмма эшне нидән башларга икәнен белмибез бит әле. Бүген мөфти янына кергәч, әлхәмдүлилләһи, сезнең бусаганы атлап керергә насыйп итте, ахырын да уңышлы итсә иде, дидем. Ул шундук ярдәм итәрдәй кеше-ләр белән элемтәгә керде, телефоннарын бирде.

Монда бит, сеңелем, эшкуар булу кирәкми, ә ниятең булу кирәк. Тормышыбыздан без бик канәгать. Кемдер бәхетне малдан, кемдер ирдән, балаларыннан күрә. Аллаһы Тәгалә безгә бәхетне башка юл белән бирде".

**Мәрьямбану ХАФИЗ**

# «ИҢ БӘХЕТЛЕ КӨННӘРЕМ»

Гөлгенә белән без институтта бергә укыдык. Яулык бөркәнгән мөслимә кыз иде ул, шуңа күрә студентлар белән күңел ачып йөргәнен хәтерләмим. Укыды да укыды, намаз вакыты җитүгә баскыч астына намаз укырга йөгерә иде. Ислам белән, намаз, гыйбадәт белән кызыксыну юк иде әле миндә ул чакта. Гөлгенәнекеннән аермалы буларак, безнең студент елларыбыз "шаулап-гөрләп" үтте. Бер кичәне, бер дискотеканы калдырмадык, кафесына, кино-театрына, концерт-тамашасына акчасын да, җаен да таптык. Тик менә гарәп хәрефен өйрәнеп, намаз догаларын ятларга гына "вакыт җитмәде". Тормыш дулкыннарында бата-калка йөзеп, лаеш шулпасын кашыклап түгел, чүмечләп чөмергәннән соң гына эзләп таптык әле без ул бердәнбер дөрес юлны.

Ә Гөлгенәбез бик тә акыллы, бәхетле кыз булган икән, адашып йөрмәгән, вакытын әрәм итмәгән. Дөрес, аның тормышы да әкияттәгедәй булмаган, мендәрен чылатып байтак төннәр уздырса уздырган, әмма тешен кысып түзгән. Беркөнне һич уйламаганда Бауман урамындагы китап кибетендә очраттым мин аны, кафега кереп, озаклап сөйләшеп утырдык.

Моннан берничә ел элек, Гөлгенә Казан егетенә кияүгә чыккан, дигән хәбәрне ишеткәч, кызлар белән бик аптырашкан идек: авыллыгы кычкырып торган, яулыклы Гөлгенә ничек карата алды икән аны, янәсе. Каратуын да караткан, матур гына яшәп тә киткәннәр болар. Гөлгенәне кайнанасы бик үз иткән. Ә менә Казан егете тора-бара хатынына суына башлаган. Гөлгенәнең "тегеләй ярамый", "болай дөрес түгел", "намаз вакыты керде" дигән сүзләреннән туйган бу.

- Минем белән кунакка йөрергә дә хурлана иде. Без бистәдә яшибез бит, урамда кара-каршы очрашсак, ул тиз генә юлның икенче ягына чыга торган иде, - ди Гөлгенә.

- Шуннан?- дим мин ачуымны көчкә тыеп.

- Шуннан шул. Ул миннән ераклаша бара, ә мин Аллага ныграк сыенам. Беләсеңме, минем өчен иң бәхетле хатын - ире артына басып намазга оеган хатын. Төннәр буе елый-елый Аллаһыдан әнә шундый бәхет сорадым. Бербер артлы ике балабыз туды, әтиләре алар өчен үлеп тора. Үзеңә генә әйтәм: бүген минем иң бәхетле көнем, беренче тапкыр ирем белән бергәләп иртәнге намазны укыдык.

**Айсылу НӘБИУЛЛИНА**

**Билгеле булганча, ислам кешене җенси тормыш алып бару мөмкинлегеннән мәхрүм итүче кастрацияне тыя. Безнең динебездә шулай ук аңлы рәвештә җенси теләкләрне зәгыйфьләндерү яки аларны даими тыеп тору да тыелган гамәлләрдән санала.**

# Буйдак булу хәраммы?



### Исламда буйдак тормыш рөхсәт ителми

Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) болай дигән: "Әгәр дә моның өчен физик һәм матди мөмкинлекләр булса, исламда буйдак тормыш юк; Аллаһы Тәгалә ир-атларга охшарга теләгән хатын-кызларны һәм хатын-кызларга охшарга теләгән ир-ат-ларны һәм шулай ук җенси тормыш алып барудан баш тартып, без өйләнмибез, без кияүгә чыкмыйбыз, дигән кешеләрне ләгънәт иткән".

### "Өйләнмәүче, өйләнүдән баш тартучы кеше – миннән түгел"

Әбү Нөҗәйх (р.г.) шундый хәдис тапшыра: "Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) әйткән: "Моның өчен физик һәм матди мөмкинлекләргә ия булып та, өйләнмәгән кеше – миннән түгел".

### Буйдак тормыш Аллаһның ләгънәтенә дучар итеlә

Әбу Умама (р.г.) тапшырган шундый хәдис бар: "Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) әйткән: "Аллаһ ләгънәт иткән һәм Аллаһтан аларны ләгънәт итүен сорап, фәрештәләр бәддога укыган һәр дүртенче кешенең берсе – аларга бала табып бирсен өчен ирекле яки кол хатын-кызлар сайлап алмаган, хатын-кызлардан читтә торырга тырышучы буйдаклар".

### Буйдаклар – шайтаннарның туганнарыдыр

Тамими кабиләсеннән булган Уккаф бине Бишр Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) янына килгәч, Пәйгамбәр (с.г.в.) аннан сораган:

- Ий Уккаф! Синең хатының бармы?

Тегесе:

- Юк, - дип җавап биргән.

Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) аннан тагын:

Ә кәнизәгең? – дип сораган.

Уккаф бусына да:

- Юк, - дип җавап биргән.

Шуннан соң Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) аннан:

- Синең матди хәлең ничек соң? - дип сораган.

- Минем матди хәлем яхшы, Аллаһның Рәсүле, - дип җавап биргән Уккаф.

Шуннан соң Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) аңа болай дигән:

- Димәк, син шайтаннарның туганнарыннан берсе. Әгәр дә христиан булсаң, син монах булыр идең. Христиан булмагач, нишләп син буйдак соң? Бездә өйләнеп яшәү кабул ителгән. Белеп торыгыз, сезнең арагызда иң начары - өйләнмәгән кеше. Хәтта мәрхүмнәр арасында да буйдаклар иң начар хәлдә калалар.

Шайтаннар үзара болай дип сөйләшәләр икән: "Шайтаннарның югары рухлы Аллаһ колларын юлдан яздыру өчен бозык хатыннардан да тәэсирлерәк коралы юк". Шайтаннар өйләнгән, гыйбадәттә ныклы һәм югары рухлы Аллаһ колларын гына юлдан яздыра алмыйлар. Чөнки алар пакьләнгәннәр, җенси тормышта тыелганнардан үзләрен саклыйлар.

Хәсрәт сиңа, Уккаф! Син хатын-кызларны кемгә саныйсың? Алар – Әюб, Давыд, Йосыф (пәйгамбәрләр) һәм Курсуф хатыннары.

Шул вакытта Атиййа бине Бишр болай дип сорап куйган:

- Ий Аллаһның Рәсүле, Курсуф кем ул?

- Курсуф – диңгез яры буенда өч йөз ел буе Раббыбызга гыйбадәт кылган Аллаһның бер колы. Ул көндез ураза тоткан, ә төнен - намаз укыган. Әмма, үзе гашыйк булган бер хатын-кыз вәсвәсәсенә бирелеп, ул Аллаһы Тәгаләне танудан һәм Аңа гыйбадәт кылудан туктаган. Ләкин Аллаһы Тәгалә элек бик күп еллар буе гыйбадәт кылган бәрәкәтләре өчен тәүбәсен кабул итеп, аны ярлыкаган.

Хәсрәт сиңа Уккаф! Син өйлән. Әгәр дә син өйләнмәсәң, иман белән имансызлык, әхлаклы тормыш белән бозык тормыш арасында һаман да икеләнәчәксең.

Уккаф моның белән килешкән һәм Пәйгамбәрдән (с.г.в.):

- Ий Аллаһның Рәсүле! Өйләндер мине! – дип үтенгән.

Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) бу үтенечне кабул итеп, аны кочаклап алган да, болай дигән:

- Мин сине Гөлсемнең кызы Кәримәгә өйләндерәм.

**Гали Риза ДЕМИРҖАН**

# ИКЕ ФРОНТЫҢ БУЛУГА КАРАГАНДА, БЕР ТЫЛЫҢ БУЛУ ЯХШЫРАК

**Сорау. Әссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ! Могтәбәр мөфти, рәхим итеп әйтегез әле, әгәр дә мөселман ир кеше икенче хатынга өйләнергә теләсә, ул бу турыда беренче хатынына әйтергә тиешме, әллә инде, ул икенче хатынның барлыгы турында, гомумән, берни дә белмәсә яхшыракмы? Ә бу вакытта ир кеше ничек итеп гадел мөнәсәбәтләр урнаштыра ала (төннәрне тигез үткәрү турында сүз бара)? *(Зәйтүнә Аширова).***

**Җавап.** Беренче сорауга килгәндә, бу тема буенча аять һәм хәдисләр, ир кеше беренче хатынына икенче хатыны турында әйтергә яки икенче хатын алу өчен аннан рөхсәт алырга тиеш, дип сөйлиләр.

Әмма, әгәр дә никахка кергән вакытта, яклар арасында ир кеше беренче хатыныннан рөхсәт алмый торып, икенче хатынга өйләнмәячәге турында килешенгән булса һәм ир кеше беренче хатыныннан рөхсәт сорамыйча икенче хатын алса, ул кабул ителгән шартны бозуы аркасында, хатын-кыз үзенә талак әйтергә һәм аннан китәргә хокуклы.

Бохара шәһәрендә шундый бер вакыйга булган. Бу шәһәрнең хатыннары галимнәргә килеп, ирләре аларны нәфкакасыз (тәэмин ителүчесез) калдыралар, шәригать шартларын бозып, аларны кыйныйлар, рөхсәтләреннән башка аларны башка шәһәрләргә алып китәләр, яшь хатын алалар, аларга игътибар итмиләр дип, ирләреннән зарланганнар. Шуннан соң Бохара галимнәре никахка керү өчен дүрт шарт куялар:

- хатынны алты ислам тәкъвиме аеннан да артык нәфәкасыз калдырмаска;
- шәригать шартларын бозып, хатыннарга сукмаска;
- хатынны әти-әниләре яшәгән шәһәрдән алып китмәскә;
- беренче хатыннан рөхсәт алмый торып, икенче хатын алмаска.

Әгәр дә шул шартларның берсе генә булса да бозылса, бу хатын "мөхәййәрәгә" (ягъни, сайлап алу хокукы булган хатынга) әйләнә. Ул үзенә талак бирергә дә мөмкин, яисә, моңа түзеп, ире белән калырга да.

Икенче сорауга килгәндә, Изге Коръәндә әйтелгән: "... әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, фәкать бер белән генә никахланыгыз ..."

Шулай ук, Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисендә болай диелгән: "Әгәр дә кемнең дә булса ике хатыны булып, ул аларга бертигез мөнәсәбәттә була алмаса, ул Кыямәт көнендә ярты ягы сөйрәлеп килүче кеше булып (ягъни ярты гәүдәсен паралич суккан кеше кебек булып) кубарылыр"

"Әл-Һидая" китабында болай диелгән: "Хатыннар тигезләүгә, төннәрне тигез үткәрүгә лаеклар, тик җенси актларның үзләрендә түгел". Мондый хәлдә, икенче хатыны барлыгы турында ир кеше үзенең беренче хатынына әйтергә мәҗбүр булачак, чөнки, аңа кайбер фактларны, мәсәлән, икенче хатынының чираты җиткәч, үзенең ни өчен өйдә булмавын яшереп тору кыен булачак.

Әгәр дә шәхсән үземнең бу мәсьәлә буенча фике-рем сезне кызыксындыра икән, мин шулай дип әйтә алам: "Ике фронтың булуга караганда бер тылың булу яхшырак".

**Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

# Иргә ничек ярарга?



Бу хакта уйланмаган хатын-кыз бармы икән җир йөзендә? Эштәме, кунактамы, берәр ял итү урыныңдамы ике-өч хатын-кыз бергә туры килсә, бу хакта сүз чыкмый калмый. "Ашарга пешкән, керләр юып үтүкләнгән, балалар караулы – никадәр тырышасың, барыбер ярап булмый бу ир-атка",- дигән фикерне хәзер дөньяви хатын-кызлар авызыннан гына түгел, мөслимәләрдән дә ишетергә туры килә. Сәбәп нидә икән соң – дөньясы үзгәрдеме, әллә үзебезме? Хатын-кызның "юка" башы мәңге җитмәслек шушы сорауга җавап эзләп, ислам сайтларында казынып утырганда ир-ат каләменнән төшкән бер язмага юлыктым. Үземә бик кызыклы тоелганлыктан, аны әлеге сәхифәдә дә урнаштырырга булдым. Хөрмәтле ханымнар, укып карагыз әле, бәхет ачкычын кулда тоту өчен, бәлки, шушы гапгади кагыйдәләрне үтәү дә җитәдер...

"Ий, мөслимә ханымнар, урамда матур итеп киенгән, бизәнгән, зифа гәүдәле, яшь, чибәр кызларны күреп, өйдә аны төсе уңган ертык халаттан, бизәнмәгән, усал чырайлы, өй җыештырып, кер юып, үтүкләп, ашарга әзерләп тирләп-пешеп беткән хатыны каршы алса, ир кеше өчен моның ничек авыр булуын беләсез микән сез?

Үтенеп сорыйбыз: ирләрегезне каршыларга һәрвакыт әзер булып торыгыз! Ул сезне күрер өчен, кочагына алып үбеп назлар өчен өенә ашкынып кайтырлык булсын. Урамда, җәмәгать урыннарында очраткан йөзләрчә кызлар томан кебек кенә тоелсын да, шул томан аша үтеп ул тизрәк өендә көтеп торган бердәнбер Кояшы җылысына омтылсын.

Белеп торыгыз: әгәр хатын-кыз үзен карамаса, аның ире башка хатынны карый башлый.

Менә шул чакта инде "ирем миңа карата игътибарсыз", "ирем соңарып кайта", "ирем иптәшләре белән еш очраша башлады", "ирем түшәктә салкынайды", "ирем минем белән аерылышырга тели", "ирем икенче хатын алырга йөри" дигән проблемалар да килеп чыгарга мөмкин.

Сез бит – хатын-кызлар! Яраткан ирләрегезне матурлыгыгыз, тарту көчегез белән әсир итегез".

**Айзилә ГАЛИЕВА**

# КЫЛЫР АЛЛАҺ ШУЛ КЕШЕГӘ РӘХМӘТЕН, МӘҮЛИД - ӘН - НӘБИНЕҢ КЫЛСА ХӨРМӘТЕН

**Данлы-шанлы дәверендә дә, дәүләтен югалткан кайгы-хәсрәтле чорында да милләтебез якты киләчәккә өметен бары тик Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның илчесенә баглаган. Чорларны узып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән касыйдәләр, мөнәҗәтләр әнә шул хакта сөйли. Дини бәйрәмнәребездә, аеруча сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) туган көндә - Мәүлид бәйрәмендә алар бүген дә мәҗлесләрдә, олы сәхнәләрдән яңгырый. Хөрмәтле укучыларыбыз, әлеге сәхифәдә шуларның кайберләрен сезнең игътибарыгызга да тәкъдим итәргә булдык.**

## “Мәүлидүн-Нәби” касыйдәсе

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим!
Әүвәл Аллаһ исмен зикер итәем,
Соңра башлап, һәр эшкә керешәем!
Эш башында кем аны зикер итәр,
Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр.
Аллаһ исмен зикер итеп эш башламак,
Һәркемгә важиб тиештер аңламак.
Булса Аллаһ исме берлә һәр эшең,
Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!
Шаукъ илә “Аллаһ” дисә кемнең теле,
Барча гөнаһы түгелер яфрак кебек!
Пакь булыр Аллаһ исмен зикер иткән,
Ирешер максадына “Аллаһ” дигән!
Килегез, чын күңелдән “Аллаһ!” диик,
Күзләрдән яшьләр түгеп без “аһ” итик.
Шулай итсәк, буш куймас Аллаһ безне,
Рәхмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.
Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк,
Сөйләгәннәр ялгышып - дөнья тулук.
Барча галәм юк икән, Ул бар иде,
Һәм әзәлдән бай иде, Җәббар иде.
Җен-фәрештә һәм адәм - берсе дә юк,
Һәм янә тугыз фәләк - һичберсе юк!
Гарше Көрси, ай-кояш һәм юк иде,
Барча җаннан әүвәл үк Ул бар иде.
Кодрәт белән боларны бар әйләде,
Берлегене барча икърар әйләде.
Бу хосуста күп сүзгә хаҗәт тә юк,
Аллаһ бердер, бардыр Ул, башкасы юк!
Әгәр шәфәгать кирәк исә әзләгез,
Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Рәсүл,
Кыл шәфәгать безләргә яумүн-нүзүл.

### Мәүлид мөнәҗәтләре

Рәсүлүлла намазда ул,
Башындадыр аның тажы;
Өммәти, өммәти, диеп
Агадыр күзендин яше.
Рәсүлүлла раузасында,
Зикер әйтеп сайрый кошлар;
Шул кошлардан гыйбрәт алып,
Салаватлар әйтик, дуслар.
Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр;
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

### Салават

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайра Халькыйллләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-
Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гааләмиин.

* * *

Әй газизләр, инде килде сүз башы,
Тыңлагыз сез агызып күз яше.
Бер васыять сөйләмәкче буламын,
Ул васыять ошбудыр, тот колагың.
Һәркем аны тыңласа, тотар исә,
Ул кешедән һәрзаман хушбуй исә.
Кылыр Аллаһ шул кешегә рәхмәтен,
Мәүлид-ән-Нәбинең кылса хөрмәтен.
Тыңлаганнар һәм табар фазыйләтен,
Укыса нәсел-нисап шәмаилен!
Рухыны шат итәек саләт илә,
Әһле бәйте, әсхабләр белән бергә.
Ул туган көннәрене хөрмәт иткән,
Тыңлар шул кыйссасыны ихлас белән.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Рәсүл,
Кыл шәфәгать безләргә яумүн-нүзүл.

* * *

Бер Хода юктан бар итте дөньяны,
Мостафаның нуры берлән нурлады.
Һәм бар итте элек шул нурыни ул,
Һәм дә барлыкның зурысы булды ул.
Ошбу нурдан күк йөзенең сафлыгы,
Ошбу нурдан җир йөзенең барлыгы.
Гарше Көрси ошбу нурдан бар була,
Дөньяның күрке шушы нурдан гына.
Булмаса ул булмас иде берни дә,
Һәм яратмас иде җирне, күкне дә.
Булмаса ул булмас иде бер адәм,
Һәм яратмас иде дөньяны тәмам.
Яратылды аның өчен һәммәсе.
Аның өчен бар итте бәндәсени.
Хак яратды хәзрәти Адәмне ул.
Һәм балкыды маңгаендан ошбу нур.
Шул сәбәпле мәртәбәле булды ул.
Ошбу нур хәлифә итте һәм аны,
Һәм фәрештәләргә юлдаш итте аны.
Сәҗдә кыйлды һәр фәрештә шул сәбәп,
Күккә ашты хөрмәти һәм шул сәгать.
Сонра бу хәл бар баласына күчеп,
Килде Габдуллага хәтле ул үсеп.
Һәм аның да маңлаенда чыкты нур,
Нәкъ кояш кебек күк ялтырады ошбу нур.
Вакты җиткәч күчте нур Габдулладан,
Балкыды ул хәзрәти Әминәдән.
Йөкле булды ул хәбибнең анасы,
Җитте туар вакты энҗү данәсе.
Әгәр шәфәгать кирәк исә әзләгез,
Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Рәсүл,
Кыл шәфәгать безләргә яумүн-нүзүл.

* * *

Әминә хатын - Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән туды энҗе данәсе.
Ул - Мөхәммәд, дөньяга хөрмәт итәр,
Вакыт җитте килмәккә хәйрел-бәшәр.
Инде аның килүе булды анык,
Күп галәмәт пәйда булды алдан ук.
Ул рабигыль-әүвәл аенда иде,
Уникенче киче, дүшәмбе иде.
“Күрдем” - диде, ул Мөхәммәд анасы,
“Бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы!
Ялт итеп чыкты өемнән шул заман,
Күкләргә тик нур белән тулды җиһан.
Һәм дә һавада түшәлде бер түшәк,
Аты сөндүс, түшәгән аны мәләк.
Өч әләм тагын куйдылар өч җиргә,
Аралары бик ерак бер-беренә.
Бере мәшрикъ, бере мәгърибтә аның,
Бересе нәкъ уртасында Кәгъбәнең.
Белдем аннан ул мөбарәкнең нурын,
Заһир булды килмәсеннән әүвәлдин.
Инде күктән күп фәрештә сафи саф,
Кәгъбә кебек кылдылар өем тәваф.
Кинәттән өч хур кызы пәйда булды,
Кайдан кергәннәрен аңлап булмады.
Өчесе дә яныма утырдылар,
“Мостафа килә!” - диеп гәп кордылар.
Диделәр: “Углың кебек хөрмәтлене,
Ул Ходай һичбер анага бирмәде!
Бик олуг дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тудырасың!
Бу угыл гыйльме ләдүн солтаныдыр,
Бу угыл тәүхиде гыйрфан кәнидер!”
Сыйфатын шул рәвешчә аңлаттылар,
Ул мөбарәк нур белән шатландырдылар!”
Диде Әминә: “Вакыт җитте тәмам,
Килә инде дөньяга хәйрел-әнәм.
Эсселектән сусадым гаять катый,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәти.
Ап-ак иде, кардан да салкын иде,
Бу кеби тәм дөньяда һич юк иде.
Эчтем аны, барча әгъзам булды нур,
Эчемә һәм тышыма да тулды нур.
Килде бер аккош канат илә очып,
Аркамнан ул сыйпады, монда төшеп.
Тугды шул сәгатьтә ул солтани дин,
Нурга тулды барлык сәмәват-зәмин.
Әгәр шәфәгать кирәк исә әзләгез,
Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Рәсүл,
Кыл шәфәгать безләргә яумүн-нүзүл.

* * *

Мәккә халкының олуглары рәвах,
Кылдылар Кәгъбәне бер кич тәваф.
Күрделәр Кәгъбәне, сәҗдә кылды ул,
Төшмәде бер ташы, кире торды шул.
Кәгъбәнең почмаклары бирде сәлам,
Диделәр: “Кем, тугды ул хәйрел-әнәм!”
Кәгъбәтулладан ишетелде сәда,
Диде: “Тугды бу кичә нур әл һуда!”
Яланаяк, башы ачык, сафи саф,
Итәчәк өммәтләре мине тәваф.
Чистартып поттан, кяфердән ул Рәсүл,
Коткарачак мине мөшрикләрдән ул!”
Фәхре галәм җитте кырык яшенә,
Пәйгамбәрлек тажын киде башына.
Инде Коръән Аллаһтан аять-аять,
Пәйда булды ничә төрле могҗизәт.
Әүвәле ул кем, мөбарәк тәненең,
Күләгәсе төшмәде җиргә аның.
Чөнки аның нур иде бар гәүдәсе,
Нурның булмас һичкайчан күләгәсе.
Аның мөбарәк баш өстендә һәрзаман,
Күләгәләп бер болыт йөрде һаман.
Мөхәммәд туган көненең кичәси,
Тулды нур белән бөтен дөнья дәхи.
Шәүләсе итте аның Шамда зуһур,
Әһле Мәккә күрделәр, кем, юк кусур.
Сүнде фарси магъбуденең утлары,
Чыкты ташып Бохәйраның сулары.
Күп гаҗәеп могҗизалар күрделәр,
Тугдыгы көн икәнлеген белделәр.
Фәхре галәм тууынча барча җан,
“Бик зур шатлык безгә,- диделәр - һаман!”
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Рәсүл,
Кыл шәфәгать безләргә яумүн-нүзүл!


### Салават

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайра Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-
Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гааләмиин.

### Мәүлид мөнәҗәтләре

Рәсүлуллаһ бораклары,
Көмештәндер тояклары;
Ихлас белән гамәл кыйлың,
Без бу дөнья кунаклары.
Ходайга гашыйк булганнар
Зикердә булганнар алар;
Шулар белән булыр өчен
Зикер әйтик, мөселманнар!
Шәфәгатен өмет итеп,
Салаватлар әйтсәк иде;
Бер Ходаем кабул итеп,
Морадларга җитсәк иде.
Ходайның дусты - Пәйгамбәр
Туган ай бу мөселманнар;
Бу ай - бәйрәм һәркем шатлык
Мөкатдәс бик шәриф ай бу.
Туды Мәккә шәһәрендә
Рабигыль-әүвәл аенда;
Дүшәмбе көн, уникенче сәхәр
Вакыты иде таң алдында.
Рәсүлуллаһ туган чакта
Сөннәтле, күзе сөрмәле;
Туу белән сәҗдә кылды,
Яуды Аллага рәхмәте.
Аңар өммәт булу белән
Безне хөрмәтләде;
Вә көн-төн, хайри өммәт, дип
Хәбәр бирде үзе.





Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Ярдәм" Сукырларны һәм начар күрүчеләрне тернәкләндерү үзәге белән берлектә уздырган Мәүлид ашына булачак коръәнхафизлар, яшь мөслимәләр, тернәкләндерү үзәгендә дәваланучы һәм Яшел Үзән районының Нурлат балалар йортында тәрбияләнүче балалар чакырылган иде. Кунаклар бәйрәм ризыклары белән сыйландылар, Ильяс Халиков башкаруында Пәйгамбәребез (с.г.в.) турында мөселман җырлары, мөнәҗәтләр тыңладылар.

**Соңгы вакытларда Татарстанда һәм бөтен Россиядә "Хизбүт-тәхрир әл-ислами" сектасы, ягъни, "Исламны азат итү фиркасе" дип аталучы оешма актив эшләп килә. Ул үз сафларына яшь мөселманнарны җәлеп итү белән шөгыльләнә һәм өммәттә фетнә чыгарырга омтыла. Алар социаль челтәрләрдә һәм интернетта аеруча активлар.**



# Сак булыгыз: "Хизбүт-тәхрир" сектасы

Хәзерге вакытта бөтен дөньяда таралыш алган секталардан мөселманнар һәм җәмгыять өчен зур куркыныч бар. Андый секталар үзләрен ислам оешмалары дип атыйлар, тик чынлыкта исә исламның кайбер положениеләрен инкарь итәләр, үзләренең билгеле бер максатларына ирешү өчен аның исеменнән файдаланалар гына.

Мөселманнарның төрле агым һәм төркемнәргә бүленәчәкләре турында Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) билгеле хәдисендә әйтелгән. Бу хәдис имам Әхмәд, әт-Тирмизи, әл-Хәким җыентыкларында китерелә һәм сәхих (ышанычлы) хәдис булып исәпләнә. Аллаһның Рәсүле болай дигән: "Минем өммәтем Исраил уллары эзеннән барып, алар кичергәннең барысын да кичерер, әгәр дә алардан кем дә булса үз әнисе белән кешеләр алдында зина кылса, минем өммәтемдә дә кем дә булса шуны ук эшләячәк. Исраил уллары 72 төркемгә бүленерләр, ә минем өммәтем - 73 төркемгә. Һәм бер төркемнән тыш калган барысы да җәһәннәм утында булырлар, шул төркем генә котылып калыр". Кешеләр аннан: "Ә ул нинди төркем булыр?" - дип сораганнар. Һәм ул: "Мин һәм минем сәхабәләрем тоткан динне тотучы төркем булыр", - дип җавап биргән".

Күренүенчә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) аның өммәтен каршылыклар көтүе турында хәбәр итә һәм бу вакытта, иң беренче чиратта, динне аңлау өлкәсендәге җитди каршылыклар күз алдында тотыла. Бүгенге көндә мөселманнар элек беркайчан да булмаган дәрәҗәдә төрле агымнарга, төркемнәргә, секталарга бүленгәннәр, мондый каршылыклар кайвакыт алар арасында бер-берләренә каршы сугышлар да китереп чыгара. Пәй-гамбәр (с.г.в.) дә бу турыда кисәткән булган. Шундый сәхих хәдис бар: "Минем өммәтемә Аллаһның, алар киләчәктәге дөньяда җәзадан азат булырлар, дигән рәхмәте бирелгән булыр. Тик моның өчен алар бу дөньяда төрле җәнҗаллар, тотрыксызлык һәм канкоешлар белән сыналырлар". Бу хәдис Әхмәднең "әл-Мөснәдендә", Әбу Давыдның "әс-Сөнәнендә", әл-Хәкимнең "әл-Мөстәдрәгендә" китерелә.

Аллаһның игелекле эшләр кылырга, игелексез эшләрдән читтә торырга дигән күрсәтмәләрен үтәп, без мөселманнарны "Хизбүт-тәхрир" оешмасының идеологиясе турында кисәтергә телибез.

**ТАРИХНЫҢ САГАЕРГА МӘҖБҮР ИТҮЧЕ ФАКТЛАРЫ**

"Хизбүт-тәхрир" фиркасен 1953 нче елда Такыйиуддин Нәбһәни (ән-Нәбһәни) оештыра. Кайбер белгечләр аны "Мөселман кардәшләре" ("әл-ихван әл-мөслимүн") дип аталучы ассоциациянең сугышчан бер канаты дип исәпләгән. Оешма вәкилләренең игълан итүе буенча, янәсе, алар үз идеологияләрен көч кулланмыйча гына тараталар. Такый-йуддин Нәбһәни үзен иҗтиһад өлкәсендә белгеч дип исәплә-гән (иҗтиһад - фикыһның компетентлы белгеченең фикыһ методологиясенә, шулай ук Коръән һәм сөннәт текстларына нигезләнеп, иҗтимагый һәм дини тормыш мәсьәләләре буенча мөстәкыйль карарлар кабул итү сәләте һәм хокукы, аларны шәрехли һәм интерпретацияли белү сәләте). Әмма, ән-Нәбһәни дини мәсьәләләрне үзендә моның өчен җитәрлек булмаган дини белемнәр шартларында шәрехләгән, шуның аркасында ялгыш юлдан киткән, ул иман һәм дин хокукы мәсьәләләрендәге иҗмаг (мөселман галимнәренең консенсусы) белән килешмәгән һәм аңа каршы чыккан.

Такыйиуддин Нәбһәни Фәләстыйнның югары мөфтие әл-Хөсәйни белән таныш булган. Ә әл-Хөсәйни икенче бөтендөнья сугышы вакытында фашистик Германиядә яшәгән һәм Адольф Гитлерга ярдәм иткән. Аннан тыш, ул "Баас" фиркасен төзүче Мишель Әфләк (гарәп белгече) белән дә таныш булган. Ән-Нәбһәни алардан финанс ярдәме һәм күп кенә идеяләрне алган. Әлбәттә, "Хизбүт-тәхрир" ән-Нәбһәнинең бу кешеләр белән таныш булуын яшереп калдырырга, күрсәтмәскә тырыша.

Хәзер "Хизбүт-тәхрир" ән-Нәбһәнинең алар белән танышлыгын яшермәгән башка кешеләргә игътибар итик. Бу, беренче чиратта, шәех Гыйз-әд-Дин әл-Кассам. Ул билгеле "мөҗәһид", сугышчы, аны киң танылу алган "Кара кул" ("әл-кафф әл-әсвад") оешмасын төзүче буларак та беләләр. Бу оешма 1930 нчы елда Британия Фәләстыйнында беренче террористик төркем булган. Оешманың бердәнбер максаты - тыныч яһүд халкын үтерү һәм алар арасында террор оештыру. Әл-Кассам үз сәяси идеяләрен нигезләр өчен Коръәннән еш кына өзекләр китерә торган булган. Ә ән-Нәбһәни шундый кешеләрдән үрнәк алган.

**АЛАРНЫҢ ЭШЧӘНЛЕК ЭТАПЛАРЫ**

Беренче этап: аерым бер кешеләрне фирка рухында, фирканең юлын, идеяләрен кабул итәрлек һәм сәяси фирка төзерлек итеп тәрбияләү.

Икенче этап: фирка идеяләрен җәмгыятьтә тулысынча тарату. Аларның идеологиясе буенча җәмгыятьнең алар идеологиясен тулысынча кабул итүе зарур.

Өченче этап: хакимияткә килү, фирка идеологияләрен тормышка ашыру, аны бар дөнья буйлап тарату.

**СЕКТАНЫҢ АЕРЫМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ**

- "Хизбүт-тәхрир" идеологиясенең дөреслеген бер генә билгеле дин галиме дә таныммый.
- "Хизүт-тәхрир"гә нигез салучы һәм аның төп идеологы илаһият нигезләре һәм дин хокукы (шәригать) мәсьәләләрендәге иҗмагларны (мөселман галимнәренең консенсуслары) танымаган. Бу "Әһле-сөннәт вәл-җәмәгать"кә һәм фикыһның гомумтанылган дүрт мәктәбе (мәзһәбе) өйрәтүләренә каршы килә;
- дөньяның күп илләрендә алар күп кешеләрнең аңнарын томалыйлар, дингә өндәү, мөселманнарга үз диннәрен аңлату урынына, мөселман яшьләрен дәүләткә каршы эшчәнлеккә тарталар;
- "Хизбүт-тәхрир" сектасы үзенең төп максаты итеп хакимияткә ирешүне куя, хәлифәт урнаштырырга өнди һәм дә ул хәлифәтне, фиркага нигез салучы Такыйиуддин Нәб-һәни күз алдына китергән формада урнаштырырга чакыра. Ә фиркага нигез салучы бу кешене мөселман дөньясында беркем дә галим итеп танымый;
- оешма сектаның бар билгеләренә дә ия - фиркадә каты буйсыну системасы бар, аның өйрәтүләре төп мәсьәләләрдә Коръән һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) урнаштырган ислам тәгълиматы положениеләреннән аерылып торалар. Фирка аерым бер төркемнәрдән тора, ул төркемнәр нибары берничә кешедән генә төзеләләр, алар башка төркемнәрнең барлыгын белмәскә дә мөмкиннәр;
- башлангыч этабында алар эшчәнлекләрен яшерен алып баралар. Аларга килеп эләккән кеше башта үзен бу фирка мәнфәгатьләренә тартуларын белмәскә дә мөмкин;
- исламның "рухи өлеше" "Хизбүт-тәхрир" өйрәтүләренең басымы астында "һәлак булып бара" дип бик кыю әйтергә була, чөнки бар дөньяда бу сектаның төп шөгыле - провокацияләр. Ә бу мөселманнарның үз диннәре өчен курка, борчыла, ислам кануннары күрсәтмәләрен тулысынча башкара алмый башлауларына китерә;
- аларның төп максаты - фетнә учагы кабызу һәм Россия ислам җәмгыятендә мөмкин кадәр күбрәк провокацияләр оештыру: анда хәл тыныч түгел, анда мөселманнарны эзәрлеклиләр, тентиләр;
- "Хизбүт-тәхрир" тарафдарлары җитәкчеләренең психологик йогынтысына дучар булалар, секта җитәкчеләре, аларга мөселманнар азчылыкны тәшкил иткән илдә утопик хәлифәт, шәригать кануннары урнаштыруны вәгъдә итеп, манипуляцияләр ясыйлар, бу вакытта алар әлеге оешманы нигезләүченең шул турыдагы фикерләрен һәм төшенчәләрен генә кулланалар;
- бу фирканең төп эшчәнлеге - Россиядә исламның һәм бу илнең гади мөселманнар белән хакимият арасында арадашчы булган дини институтларының кулларын бәйләү. Аларның эшчәнлегенең бердәнбер нәтиҗәсе - мәчетләрне ябу, мөселманнарны кулга алу, алар үз пропагандалары белән, кешеләрнең шәхси уңышсызлыкларында һәм илдәге социаль җитешсезлекләрдә хакимиятне гаепләргә тырышып, яшь мөселманнарны хакимияткә каршы чыгыш ясарга тарталар;
- үз эшчәнлекләрен һәм хокукларын алар бары тик эмоциональ һәм провокацион эшләре белән генә дәлилилиләр, мөселманнарның дини хисләрендә уйнап, аларның ихлас ул хисләрен үз максатларына ирешү өчен файдаланалар;
- алар ислам өчен бернинди файдалы эш белән дә шөгыльләнмиләр, ә утопик хәлифәт өчен дәүләткә каршы көрәшкә генә өндиләр, өстәвенә ул хәлифәтнең нәкъ менә алар теләгән вариантында. Бу фирка вәкилләре бар дөньяда бер генә мәчет тә төземәде, бер генә мәдрәсә дә ачмады, аларның тәнкыйтьләре бер генә жирдә дә конструктив түгел, ә эшчәнлекләре - диалогка һәм барлыкка китерүгә юнәлтелмәгән.

**"ХИЗБҮТ-ТӘХРИР" ҺӘМ "ӘҺЛЕ СӨННӘТ ВӘЛ-ҖӘМӘГАТЬ" АРАСЫНДАГЫ ИДЕОЛОГИК КАРШЫЛЫКЛАР**

- "Хизбүт-тәхрир" фиркасе вәкилләре иман нигезләренең берсен - барысының да Аллаһы Тәгалә тарафыннан тәкъдирләнүенә инануны инкарь итәләр;
- "Хизбүт-тәхрир" фиркасе вәкилләре пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр (аларга Аллаһның сәламе булсын!), алар пәйгамбәрлеккә ирешкәнче, имансызлыктан, зур һәм, шулай ук, кече гөнаһлардан сакланган булмаган дип раслыйлар, ә аларны кылу - аларны кылган кешенең юньсезлеген, гөнаһлылыгын күрсәтә;
- "Хизбүт-тәхрир" вәкилләре фикере буенча хәлифәт булмаганда шәригатьнең шактый өлеше тормышта үтәлмәсә дә ярый. Мәсәлән, алар тәмәке тартырга, җенси мөнәсәбәт, якынлык турында фильмнар карарга (ул хәрам гамәлләрдән санала) рөхсәт итәләр;
- "Хизбүт-тәхрир" фиркасе вәкилләре, кем Хәлифәгә үлгәнгә кадәр дип ант итми, ул җаһилият (исламга кадәрге мәҗүсилек) чоры үлеме белән үлә, дип раслыйлар;
- "Хизбүт-тәхрир" фиркасе вәкилләре үзләре ниндидер карарга килә ала торган һәркем мөҗәһид булырга, ягъни, җәмгыять һәм диннең мөһим мәсьәләләре буенча мөстәкыйль карарлар кабул итәргә хокуклы дип раслыйлар.

**P.S.** "Хизбүт-тәхрир" 2003 нче елда антисемит пропагандасы, неофашистик оешмалар белән хезмәттәшлеге, көч куллануга чакыруы өчен Германиядә тыелды. Шуннан соң Хизбүт-тәхрир" Европа мәхкамәсенә шикаять язды, ләкин 2012 нче елны бу шикаятьне мәхкамә кире какты.

Россия Федерациясендә "Хизбүт-тәхрир"нең эшчәнлеге террористик булып танылган һәм Россиянең ФСБ материаллары һәм инициативасы, РФнең Генераль прокуратурасы бирелеше нигезендә РФнең Югары Мәхкамәсе белән 2003 нче елның февраленнән тыелган. Шуңа күрә дә бу оешманың эшчәнлегендә катнашу җинаять җаваплыгына тартыла һәм закон белән эзәрлекләнә!

**Мөселманнар, "Хизбүт-тәхрир" сектасы провокацияләренә бирелмәгез!**

**2014 нче елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр (һиҗри буенча 1435-1436 нчы еллар)**

**12-13 нче гыйнвар –** Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе - Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көне. Бу изге бәйрәм бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә.

**21 нче май –** Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн.

**1-2 нче май** – рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич - Рәгаиб кичәсе. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) атиәнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**25-26 нчы июнь** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә - Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте.

**12-13 нче июнь** – Бәраәт кичәсе. Бәхет һәм изгелекләр иңә торган көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлен һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**28 нче июнь –** изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

**28 нче июль –** Ураза бәйрәме.

**3 нче октябрь** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучыларның Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**4 нче октябрь –** Корбан бәйрәме. Ул 3 көн дәвам итә.

**25 нче октябрь –** һиҗри буенча яңа мөселман елы һәм мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**3 нче ноябрь –** Гашурә бәйрәме.

**18-19 декабрь** – Һиҗрәт кичәсе һәм көне. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көне. Шушы көннән, ягъни 622 нче елның 16 нчы июленнән мөселман ел исәбе - һиҗри ел исәбе башлана.

# “ТАЯН АЛЛАГА”

Әдәби сүз, иҗат аша исламдагы югары рухый кыйммәтләргә игътибар юнәлтү, мөселманнар тормышын, динебез кыйммәтләрен әдәби әсәрләр-дә яктырту һәм иманлы буын тәрбияләү ниятеннән Россия ислам институты Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән берлектә "Таян Аллага" дүртенче әдәби конкурсын игълан итә.

Әсәрләрне җыю 2014 нче елның мартына кадәр дәвам итә.

Конкурста Татарстан һәм татарлар яши торган төбәкләрдән һәрбер теләгән кеше катнаша ала. Әсәрләр татар телендә электрон вариантта кабул ителә. Конкурс өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәрләр, драматургия. Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) өчтән дә ким булмаска тиеш.

Һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннар һәм гран-при билгеләнә.

Конкурс нәтиҗәләре буенча «Таян Аллага» исемле җыентык чыгарыла. Ул конкурска килгән иң яхшы әсәрләрдән тупланачак.

Оештыру комитеты адресы: **Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт, 312 каб.; тел.: (843) 277-58-12, 238-17-61; e-mail: tayanallga@yandex.ru**

# "ХУЗУР"ДА ЯҢА КИТАПЛАР

"Хузур" нәшрият йортында шушы көннәрдә генә тагын берничә китап басылып чыкты.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның "һәркем коръәнхафиз була ала" ("Каждый может стать Коран хафизом") дип аталган китабын Коръәнне яттан өйрәнергә теләүчеләр әсбап итеп куллана ала. Ул Изге китап тарихы һәм аны уку, яттан сөйләү культурасы белән кызыксынучылар өчен дә файдалы булачак.

Хәнәфи мәзһәбенең нигезе саналган "Мохтасар әл-Кудури" китабы да нәшер ителде. Әхмәд бин Мөхәммәд Әбелхөсәен әл Кудури (428/1037) хезмәте хакында мәшһүр дин галиме Абугали аш-Шаши (344/955) болай дигән: "Бу китапны өйрәнгән кеше безнең мәзһәбне үзенә кабул итә, ә кем бу китапны аңлый – мәзһәбне дә яхшырак аңлый".

Нәшрият йортының мөселман кардәшләребезгә тагын бер бүләге бар. Изге Коръәннең яңа басмасы (Казан басмасы) 10 мең тираж белән яңа дизайнда нәшер ителде. Коръән Татарстанның барлык мәчетләренә һәм мәхәлләләренә бушка таратылачак.

"Хузур" нәшрият йорты чыгарган китапларны сатып алырга теләүчеләр ***8(843) 202 07 74; 8 965 596 55 37*** телефоннары буенча мөрәҗәгать итә ала.

# Быелгы ХАҖ СЕЗОНЫ ачык!

Хаҗ гыйбадәтен үтәргә баруны оештыру һәм аны үтәү – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең иң төп юнәлешләренең берсе, чөнки хаҗ кылу динебездә мөселманга фарыз булган бишенче багана. Шуңа бәйле рәвештә, Аллаһ исеме белән, без 2014 нче ел хаҗ сезонын ачык дип игълан итәбез.

Без быел да хаҗиларга хезмәт күрсәтүне "Барысы да кертелгән" («Все включено») дип исемләнгән яңа стандарт буенча алып баруны дәвам иттерәчәкбез. Хезмәт күрсәтүнең әлеге төре гыйбадәтне үтәүнең барлык мәҗбүри (фарыз, ваҗиб) һәм өстәмә (сөннәт, мөстәхәб) шартларын үз эченә ала.

Моңа өстәп, тагын башка мәсьәләләр, әйтик, туклану турында да әйтеп узасым килә. Согуд Гарәбстаны Корольлеге җирләрендә, хәтта Мина һәм Гарәфәт үзәнлекләрендә булганда да без хаҗиларның ашауэчүен оештыруны исебездән чыгармыйбыз. Без моны хаҗиларыбыз шикле, санитария таләпләренә җавап бирмәгән сәүдә рәтләреннән файдаланмасын өчен эшлибез; шул ук вакытта безнең ашамлыклар һәм хезмәткәрләр дәүләт санитар күзәтүе һәм табиб тикшерүе уза.

2014 нче ел өчен төзелгән «ДУМ РТ ХАДЖ» программасы шулай ук түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) хаҗ гамәлләрен Хәнәфи мәзһәбе буенча башкару;

2) хаҗ гыйбадәтен үтәү, укыту һәм татар телендә вәгазьләр бирү;

3) бар яктан да уңайлы заманча очкычларда Согуд Гарәбстанына очу һәм кире әйләнеп кайту;

4) Мәккә шәһәрендә Әл-Хәрәм мәчетеннән өч километрга кадәр аралыкта яшәүне тәэмин итү;

5) сәфәрнең дәвамлылыгы 20-30 көн;

6) Мәдинә шәһәрендә 5 көнгә кадәр яшәү;

7) медицина иминияте; бер енче медицина ярдәме һәрвакыт хаҗилар белән янәшә;

8) кунакханәнең бер бүлмәсендә кешеләрнең саны – дүрттән сигезгә кадәр;

9) Мәдинә һәм Мәккә кунакханәләрендә көненә ике тапкыр туклану;

10) 45 кешелек һәр төркемдә имам-җитәкче;

11) Согуд Гарәбстаны Корольлегендә транспорт чаралары белән тулысынча тәэмин ителеш;

12) 10 литр зәмзәм суы;

13) кирәкле әдәбият;

14) корбан чалу;


15) ир-атлар өчен ихрам кием;

16) Согуд Гарәбстаны Корольлегенең җирле SIM-карталары.

Шулай ук мөхтәсибләрдән хаҗ вакытына имам-җитәкче вазыйфасына намзәдләр (кандидатлар) көтеп калабыз.

**Хәбибулла (Руслан) НӘФИСУЛЛИН, "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы җитәкчесе**





***"ДУМ РТ ХАДЖ" белән түбәндәге телефоннар аша элемтәгә керергә мөмкин: +7 (843) 524-92-10, +7 (843) 240-53-98, +7 (843) 200-93-11, 8-800-555-92-10. Адресыбыз: 420021, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт. Интернеттагы сайт: www.dumrt-haj.ru. Электрон почта адресы: 5249210@gmail.com.***

Дин вә Мәгыйшәт

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*
**Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Гыйнвар саны, № 1 (222)**

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*Татарстан мөфтие урынбасары **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДҺӘМОВ**.*

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09607.
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **27 нче гыйнвар көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**